ИНСПЕКЦИЯ
ГОСУДАРСТВЕННОГО
СТРОИТЕЛЬНОГО НАДЗОРА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
420111, г. Казань, ул.Б. Красная, 15/9

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
ДӘҮЛӘТ ТӨЗЕЛЕШЕН
КҮЗӘТҮ ИНСПЕКЦИЯСЕ
420111, Казан ш., Зур Кызыл ур., 15/9

Тел.: (843) 299-78-18, факс (843) 299-19-35, e-mail: gsn@tatar.ru, http://gsn.tatar.ru
ОКПО 04010768, ОГРН 1081690004164, ИНН 1655151073, КПП 165501001

**№ 94**

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

**«04 » декабрь 2013 ел**

**Татарстан Республикасы
Дәүләт төзелешен күзәтү инспекциясенең
Татарстан Республикасында региональ
дәүләт төзелешен күзәтү буенча дәүләт
функциясен башкаруының Административ
регламентын раслау турында**

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2012 ел, 31 декабрьдән “Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарының дәүләт функцияләрен башкаруының административ регламентларын эшләү һәм раслау Тәртибен раслау турында”гы 1192 номерлы, 2007 ел, 12 ноябрьдән “Татарстан Республикасының Дәүләт төзелешен күзәтү инспекциясе мәсьәләләре” турындагы 622 номерлы карарлары нигезендә, Татарстан Республикасында региональ дәүләт төзелешен күзәтү буенча дәүләт функциясен башкаруның нәтиҗәлелеген арттыру максатларында,

Б О Е Р А М:

1. Әлеге боерыкка теркәлүче Татарстан Республикасы Дәүләт төзелешен күзәтү инспекциясенең Татарстан Республикасында региональ дәүләт төзелешен күзәтү буенча дәүләт функциясен башкаруының Административ регламентын (алга таба - Регламент) расларга.

2. Башлык урынбасарларына, структура бүлекләрендәге җитәкчеләргә, дәүләт төзелешен күзәтүне турыдан-туры башкаручы затларга:

2.1. практик эшчәнлектә Регламент нигезләмәләреннән генә файдаланып эш итәргә;

2.2. Татарстан Республикасы Дәүләт төзелешен күзәтү инспекциясе белгечләренең Регламентны өйрәнүен һәм анда каралган тиешле документларны (шул исәптән мәгълүмати материалларны рәсмиләштерүне) тулы күләмдә алып баруны тәэмин итәргә.

3. Инспекциянең мәгълүмати-техник бүлеге башлыгы С.Г. Вишняковага әлеге боерык белән расланган Регламентны Татарстан Республикасы Хөкүмәтенең Рәсми порталындагы Татарстан Республикасы Дәүләт төзелешен күзәтү инспекциясенең субпорталында һәм Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр

порталында “Дәүләт органнары һәм җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турындагы мәгълүмат алуны тәэмин итү турында”гы Федераль закон нигезләмәләренә ярашлы итеп урнаштырырга.

4. Юридик бүлек башлыгына (Фатыйхов Р.З.) әлеге боерыкның Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында теркәлүен тәэмин итәргә һәм аны рәсми бастырып чыгаруга юлларга.

5. Әлеге боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башлык Кудряшов В.А.

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
Дәүләт төзелешен күзәтү инспекциясе
боерыгы белән
РАСЛАНДЫ
04.12. 2013 ел, № 94

**Татарстан Республикасы Дәүләт төзелешен күзәтү инспекциясенең Татарстан Республикасында региональ дәүләт төзелешен күзәтү буенча дәүләт функциясен башкаруының Административ регламенты**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Административ регламент (алга таба – Регламент) "Татарстан Республикасында региональ дәүләт төзелешен күзәтүне башкару" (алга таба – дәүләт төзелешен күзәтү) дәүләт функциясен тормышка ашырганда Татарстан Республикасы Дәүләт төзелешен күзәтү инспекциясенең (алга таба - Инспекция) административ процедураларын һәм административ эшчәнлегенең вакытларын һәм эзлеклелеген билгели.

1.2. Дәүләт төзелешен күзәтү Инспекциясе һәм Инспекция структурасына караучы, аның капиталь төзелеш объектларының төзелешен һәм үзгәртеп корылышын күзәтү буенча территориаль органнары (алга таба – Инспекциянең территориаль органнары) тарафыннан башкарыла.

Дәүләт төзелешен күзәтү турыдан-туры Инспекция башлыгының (башлык урынбасарының, территориаль орган җитәкчесенең) тиешле боерыгы (әмере) нигезендә дәүләт төзелешен күзәтүгә вәкаләтле булган һәм Инспекция башлыгының (башлык урынбасарының, территориаль орган җитәкчесенең) тикшерү үткәрү турындагы боерыгы (әмере) белән билгеләнгән Инспекциядәге вазыйфаи затлары (алга таба – вазыйфаи затлар) тарафыннан тормышка ашырыла.

Дәүләт төзелешен күзәтү Регламентның 1.4 пунктында күрсәтелгән капиталь төзелеш объектлары төзелеше, үзгәртеп корылышы барышында юридик затларга, шәхси эшмәкәрләргә, физик затларга карата тикшерү үткәрү формасында башкарыла.

Дәүләт төзелешен күзәтү Инспекция тарафыннан прокуратура, үзен-үзе көйләүче оешмалар, эксперт оешмалары, дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, юридик затлар һәм шәхси эшмәкәрләр, гражданнар белән аларның мөрәҗәгатьләре буенча үзара булышлык итү нигезендә башкарыла.

Инспекциянең территориаль органнары тарафыннан тикшерүләр үткәрү, лаборатор һәм/яки башкарылган эшләрне һәм төзелеш материалларын/эшләнмәләрен башка төр тәҗрибәләргә дучар итү таләп ителгән тикшерүләрне үткәргәндә Инспекциянең Инспекция структурасына караган Экспертизалар, тикшеренүләр һәм тәҗрибәләр үткәрүне күзәтү буенча территориаль органы (алга таба – Экспертизаларны үткәрүне күзәтү буенча территориаль орган) җәлеп ителә.

Экспертизаларны үткәрүне күзәтү буенча территориаль орган тарафыннан бәя кую, яисә үз көче белән лаборатор-инструменталь контрольлек итү, шулай ук төрле

экспертизалар үткәрү мөмкинлеге булмаганда, законнарда каралган тәртиптә, экспертлар һәм эксперт оешмалары җәлеп ителә.

1.3. Дәүләт төзелешен күзәтү түбәндәгеләр нигезендә тормышка ашырыла:

Россия Федерациясенең Шәһәр төзелеше кодексы (алга таба – РФ ШрК) (Россия Федерациясенең Законнар җыелмасы, 2005, № 1 (1 б.), 16 ст.; № 30 (2 б.), 3128 ст.; 2006, № 1, 10 ст., 21 ст.; № 23, 2380 ст.; № 31 (1б.), 3442 ст.; № 50, 5279 ст.; № 52 (1б.), 5498 ст.; 2007, № 1 (1б.), 21 ст.; № 21, 2455 ст.; № 31, 4012 ст.; № 45, 5417 ст.; № 46, 5553 ст.; № 50, 6237 ст.; 2008, № 20, 2251 ст., 2260; № 29 (1б.), 3418 ст.; № 30 (1б.), 3604 ст.; № 30 (2б.), 3616 ст.; № 52 (1б.), 6236 ст.; 2009, № 1, 17 ст.; № 29, 3601 ст.; № 48, 5711 ст.; № 52 (1б.), 6419 ст.; 2010, № 31, 4195 ст., 4209; № 48, 6246 ст.; № 49, 6410 ст.; 2011, N 13, 1688 ст.; № 17, 2310 ст.; № 27, 3880 ст.; № 29, 4281 ст., 4291; № 30 (1б.), 4563 ст., 4572, 4590, 4591, 4594, 4605; № 49 (1б.), 7015 ст., 7042; № 50, 7343 ст.; 2012, № 26, 3446 ст.; № 30, 4171 ст.; № 31, 4322 ст.; № 47, 6390 ст.; № 53 (1б.), 7614, 7619,7643 ст.; 2013, № 9, 873, 874 ст.);

Россия Федерациясенең Административ хокук бозулар буенча кодексы белән (алга таба – РФ КоАП) (Россия Федерациясенең Законнар җыелмасы, 2002, № 1 ( 1б.), 1 ст.; № 18, 1721 ст.; № 30, 3029 ст.; № 44, 4295 ст. , 4298; 2003, № 1, 2 ст.; № 27 (1б.), 2700 ст.; № 27 (2б.), 2708 ст., 2717; № 46 (1б.), 4434 ст., 4440; № 50, 4847, 4855 ст.; № 52 (1б.), 5037 ст.; 2004, № 19 (1б.), 1838 ст.; N 30, 3095 ст.; N 31, 3229 ст.; N 34, 3529 , 3533 ст.; N 44, 4266 ст.; 2005, N 1 (1б.), 9, 13, 37, 40, 45 ст.; N 10, 762, 763 ст.; N 13, 1077, 1079 ст.; N 17, 1484 ст.; N 19, 1752 ст.; N 25, 2431 ст.; N 27, 2719 , 2721 ст.; N 30 (1б.), 3104 ст.; N 30 (2б.), 3124, 3131 ст.; N 40, 3986 ст.; N 50, 5247 ст.; N 52 (1б.), 5574, 5596 ст.; 2006, N 1, 4, 10 ст.; N 2, 172, 175 ст.; N 6, 636 ст.; N 10, 1067 ст.; N 12, 1234 ст.; N 17 (1б.), 1776 ст.; N 18, 1907 ст.; N 19, 2066 ст.; N 23, 2380, 2385 ст.; N 28, 2975 ст.; N 30, 3287 ст.; N 31 (1б.), 3420, 3432, 3433, 3438, 3452 ст.; N 43, 4412 ст.; N 45, 4633, 4634, 4641 ст.; N 50, 5279, 5281 ст.; N 52 (1б.), 5498 ст.; 2007, N 1 (1б.), 21, 25, 29, 33 ст.; N 7, 840 ст.; N 15, 1743 ст.; N 16, 1824, 1825 ст.; N 17, 1930 ст.; N 20, 2367 ст.; N 21, 2456 ст.; N 26, 3089 ст.; N 30, 3755 ст.; N 31, 4001, 4007, 4008, 4015 ст.; N 41, 4845 ст.; N 43, 5084 ст.; N 46, 5553 ст.; N 49, 6034, 6065 ст.; N 50, 6246; 2008 ст., N 10 (1б.), 896 ст.; N 18, 1941 ст.; N 20, 2251, 2259 ст.; N 29 (1б.), 3418 ст.; N 30 (1б.), 3582, 3601, 3604 ст.; N 45, 5143 ст.; N 49, 5738 ст., 5745 ст., 5748 ст.; N 52, 6227 ст., 6235 ст., 6236 ст., 6248 ст.; 2009, N 1, 17 ст.; N 7, 771 ст., 777 ст.; N 19, 2276 ст.; N 23, 2759 ст., 2767 ст., 2776 ст.; N 26, 3120 ст., 3122 ст., 3131 ст., 3132 ст.; N 29, 3597 ст., 3599 ст., 3635 ст., 3642 ст.; N 30, 3735 ст., 3739 ст.; N 45, 5265 ст., 5267 ст.; N 48, 5711 ст., 5724 ст., 5755 ст.; N 52, 6406 ст., 6412 ст.; 2010, N 1, 1 ст.; N 11, 1169 ст., 1176 ст.; N 15, 1743 ст., 1751 ст.; N 18, 2145 ст.; N 19, 2291 ст.; N 21, 2524 ст., 2525 ст., 2526 ст., 2530 ст.; N 23, 2790 ст.; N 25, 3070 ст.; N 27, 3416 ст., 3429 ст.; N 28, 3553 ст.; N 29, 3983 ст.; N 30, 4000 ст., 4002 ст., 4005 ст., 4006 ст., 4007 ст.; N 31, 4155 ст. , 4158 ст., 4164 ст., 4191 ст., 4192 ст. , 4193 ст., 4195 ст., 4198 ст., 4206 ст. , 4207 ст., 4208 ст.; N 41, 5192 ст.; N 46, 5918 ст.; N 49, 6409 ст.; N 50, 6605 ст.; N 52, 6984 ст. , 6996 ст. ; 2011, N 1, 23 ст., N 1, 29 ст. , N 1, 33 ст. , N 7, 901 ст., N 1, N 7, 905 ст., 54 ст., N 15, 2041 ст., N 17, 2312 ст., N 19, 2714 ст., N 19, 2715 ст., N 19, 2769 ст. ; N 23, 3267 ст.; 3260 ст.; N 27, 3873 ст., N 29, 4289 ст., N 29, 4290 ст., N 29, 4291 ст., N 30 (1б.), 4573 ст., N 30 (1б.), 4584 ст., N 30 (1б.), 4590 ст. , N 30 (1б.), 4591 ст., N 30 (1б.), 4598 ст., N 30 (1б.), 4601 ст., N 45, 6325 ст., 6326 ст., 6334 ст., N 46, 6406 ст., N 47, 6601 ст., 6602

ст., N 48, 6730, 6732 ст., N 49, 7025 ст., 7042 ст., 7056 ст., 7061 ст., N 50, 7345, 7346 ст., 7351 ст., 7352 ст., 7355 ст., 7362 ст., 7366 ст.; 2012, N 6, 621 ст.; N 10, 1166 ст., N 15, 1723 ст., 1724, N 18, 2126 ст., N 19, 2278, 2281 ст.; N 24, 3068, 3069, 3082 ст.; N 29, 3996 ст.; N 31, 4320, 4322, 4329, 4330 ст.; N 41, 5523 ст.; N 47, 6402, 6403, 6404, 6405 ст.; N 49, 6752, 6757 ст.; N 53 (1б.), 7577, 7580, 7602, 7639, 7640, 7641, 7643 ст.; 2013, N 8, 717, 718, 719, 720 ст.);

2008 ел, 26 декабрьдән “Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне тормышка ашырганда юридик затларның һәм шәхси эшмәкәрләрнең хокукларын яклау турында”гы 294-ФЗ номерлы Федераль закон белән (алга таба – 294-ФЗ номерлы Федераль закон) (Россия Федерациясенең Законнар җыелмасы, 2008, N 52 (1б.), 6249 ст.; 2009, N 18 (1б.), 2140 ст.; N 29, 3601 ст.; N 48, 5711 ст.; N 52 (1б.), 6441 ст.; 2010, N 17, 1988 ст., N 18, 2142 ст., N 31, 4160, 4193, 4196 ст.; N 32, 4298 ст.; 2011, N 1, 20 ст., N 17, 2310 ст., N 23, 3263 ст., N 27, 3880 ст., N 30 (1б.), 4590 ст., N 48, 6728 ст.; 2012, N 19, 2281 ст., N 26, 3446 ст., N 31, 4320 ст., 4322, N 47, 6402 ст.);

2002 елның 27 декабреннән “Техник көйләү турында”гы 184-ФЗ номерлы Федераль закон белән (Россия Федерациясенең Законнар җыелмасы, 2002, N 52 (1б.), 5140 ст., 2005, N 19, 1752 ст., 2007, N 19, 2293 ст., N 49, 6070 ст., 2008, N 30 (2б.), 3616 ст., 2009, N 29, 3626 ст., N 48, 5711 ст.,2010, N 1, 5,6 ст., N 40, 4969 ст., 2011, N 30 (1б.), 4603 ст., N 49 (1б.), 7025 ст., N 50, 7351 ст.; 2012, N 31, 4322 ст., N 50 (5б.), 6959 ст.);

2009 елның 30 декабреннән “Биналарның һәм корылмаларның куркынычсызылыгы турында техник регламент” 384-ФЗ номерлы Федераль закон белән (Россия Федерациясенең Законнар җыелмасы, 2010, N 1, 5 ст.);

2008 елның 22 июленнән “Янгын куркынычсызлыгы таләпләре турында техник регламент” 123-ФЗ номерлы Федераль закон белән (Россия Федерациясенең Законнар җыелмасы, 2008, N 30 (1б.), 3579, 2012 ст., N 29, 3997 ст.);

2006 елның 2 маеннан “Россия Федерациясе гражданнары мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында”гы 59-ФЗ номерлы Федераль закон белән (алга таба – 59-ФЗ номерлы Федераль закон) (Россия Федерациясенең Законнар җыелмасы, 2006, N 19, 2060, 2010 ст., N 27, 3410, N 31 ст., 4196 ст.);

2009 елның 23 ноябреннән “Энергияне саклау турында һәм энергия нәтиҗәлелеген арттыру турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында”гы 261-ФЗ номерлы Федераль закон белән (Россия Федерациясенең Законнар җыелмасы, 2009, № 48, 5711, 2010 ст., N 19, 2291 ст., № 31, 4160, 4206, 2011 ст., № 29, 4288, 4291 ст., № 30 (1б.), 4590 ст., № 49 (5б.), 7061 ст., № 50, 7344 ст., 7359, № 51, 7447; 2012 ст., № 26, 3446 ст., № 29, 3989 ст., № 53 (1б.), 7595 ст.);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2006 елның 1 февраленнән “Россия Федерациясендә дәүләт төзелешен күзәтү турында”гы 54 номерлы карары белән (Россия Федерациясенең Законнар җыелмасы, 2006, N 7, 774 ст.; 2008, N 8, 744 ст.; 2009, N 11, 1304 ст.; 2011, N 7, 979 ст., N 18, 2645 ст.; 2012, N 7, 864 ст.);

2006 елның 26 декабреннән Экологик, технологик һәм атом күзәтчелеге буенча федераль хезмәтнең “Капиталь төзелеш объектларының төзелеше, үзгәртеп корылышы, капиталь төзекләндерелешендәге башкарма документларны алып баруның составына һәм тәртибенә карата Таләпләрне һәм эшләрне,

конструкцияләрне, инженер-техник тәэмин ителеш челтәрләре кишәрлекләрен карап чыгу актларына карата таләпләрне раслау һәм кулланылышка кертү турында”гы 1128 номерлы боерыгы белән (РФ Юстиция министрлыгында 06.03.2007 елда 9050 номеры белән теркәлгән) (“Башкарма хакимият федераль органнарының норматив актлары бюллетене”, № 13, 26.03.2007);

Экологик, технологик һәм атом күзәтчелеге буенча федераль хезмәтнең 2006 елның 26 декабреннән “Дәүләт төзелешен күзәтүне тормышка ашырганда тикшерүләр үткәрү һәм төзелгән, үзгәртеп корылган, төзекләндерелгән капиталь төзелеш объектларының техник регламентларның (нормаларның һәм кагыйдәләрнең), башка төр норматив актларның, проект документларының таләпләренә ярашуы турындагы бәяләмәләрне бирү Тәртибен раслау һәм кулланылышка кертү турында”гы 1129 номерлы боерыгы белән (РФ Юстиция министрлыгында 06.03.2007ел, 9053 номеры белән теркәлгән) (“Башкарма хакимият федераль органнарының норматив актлары бюллетене”, № 15, 09.04.2007) (алга таба – Ростехнадзорның 26.12.2006 ел, 1129 номерлы боерыгы);

Экологик, технологик һәм атом күзәтчелеге буенча федераль хезмәтнең 2006 елның 26 декабреннән “Дәүләт төзелешен күзәтүне тормышка ашырганда эшләрне рәсмиләштерү һәм алып баруның Тәртибен раслау һәм кулланылышка кертү турында”гы 1130 номерлы боерыгы белән (РФ Юстиция министрлыгында 05.03.2007ел, 9009 номеры белән теркәлгән) (“Башкарма хакимият федераль органнарының норматив актлары бюллетене”, № 13, 26.03.2007) (алга таба - Ростехнадзорның 26.12.2006 ел, 1130 номерлы боерыгы);

Экологик, технологик һәм атом күзәтчелеге буенча федераль хезмәтнең 2007 елның 12 гыйнварыннан “Капиталь төзелеш объектларының төзелеше, үзгәртеп корылышы, капиталь төзекләндерелеше барышында башкарылган эшләрне исәпкә алуның гомуми һәм (яисә) махсус журналын алып бару Тәртибен раслау һәм кулланылышка кертү турында”гы 7 номерлы боерыгы белән (РФ Юстиция министрлыгында 06.03.2007ел, № 9051 белән теркәлгән) (“Башкарма хакимият федераль органнарының норматив актлары бюллетене”, 2007, № 14);

Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгының 2009 елның 30 апреленнән “Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне тормышка ашырганда юридик затларның һәм шәхси эшмәкәрләрнең хокукларын яклау турында”гы Федераль закон нигезләмәләрен тормышка ашыру турында”гы 141 номерлы карары белән (РФ Юстиция министрлыгында 13.05.2009 ел, 13915 номеры белән теркәлгән) (“Российская газета”, 2009, N 85) (алга таба – Икътисадый үсеш министрлыгы карары, 30.04.2009 ел, № 141);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 елның 12 ноябреннән 622 номерлы “Татарстан Республикасы Дәүләт төзелешен күзәтү инспекциясе мәсьәләләре” карары белән (“Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының карарлар һәм боерыклар һәм республика башкарма хакимияте органнарының норматив актлар җыентыгы”, 2007, № 43, 1707 ст.).

1.4. Дәүләт төзелешен күзәтү (алга таба – дәүләт төзелешен күзәтү) түбәндәге очракларда башкарыла:

1) проект документлары РФ ШТК 49 статьясы нигезендә экспертизага тиешле булган яисә типлаштырылган яисә аның модификациясе булган капиталь төзелеш объектларының төзелешендә;

2) капиталь төзелеш объектларының үзгәртеп корылышы барышында, әгәр дә капиталь төзелеш объектының үзгәртеп коруга карата проект документлары РФ ШрК 49 статьясы нигезендә экспертизага тиешле булса.

Дәүләт төзелешен күзәтү, үзгәртеп корылышы барышында дәүләт төзелешен күзәтү каралган капиталь төзелеш объектларының төзелеше, үзгәртеп корылышы барышында тормышка ашырыла, түбәндәге очраклардан тыш:

1) капиталь төзелеш объектының төзелешен, үзгәртеп корылышын дәүләт төзелешен күзәтү башкарма хакимиятнең дәүләт төзелешен күзәтүгә вәкаләт бирелгән федераль органы тарафыннан башкарылганда;

2) төзелеше, үзгәртеп корылышы өчен төзелешкә рөхсәт кәгазе таләп ителмәгән капиталь төзелеш объектларында, шулай ук дәүләт экспертизасыннан яисә дәүләти булмаган экспертизадан уңай бәяләмә алган капиталь төзелеш объектларының проект документларына карата мондый экспертиза үткәрелгәндә һәм кабат үткәрелгәндә (алга таба – типлаштырылган проект документлары), яисә капиталь төзелеш объектларының конструктив һәм ышанычлылык һәм куркынычсызлыкның башка бәяләмәләренә кагылмаучы мондый проект документларының модификациясе, яисә чик буе объектларының төзелеше яисә үзгәртеп корылышы барышында проект документлары экспертизасыннан (шул исәптән – проект документларының аерым бүлекләренә) уңай бәяләмә алган, чик буе объектларының конструктив һәм ышанычлылыгының һәм куркынычсызлыгының башка бәяләмәләрен һәм чик буе объектларының куркынычсызлыгын киметмәүче һәм, күрсәтелгән проект документлары модификациясе чик буе объектларының төзелешенә, үзгәртеп корылышына булган сметаның артуына китермәгән очракта, аларның сыйфат һәм функцияләү бәяләмәләрен үзгәртмәүче модификация кулланылган очракта;

3) проект документлары экспертизага тиешле булмаган капиталь төзелеш объектларында.

Экспертиза түбәндәге капиталь төзелеш объектлары төзелешенең проект документларына карата үткәрелми:

1) өч каттан да артмаган аерым торучы, бер гаиләгә ниятләнгән торак йортлар (шәхси торак төзелеше объектлары);

2) өч каттан да артмаган, саны уннан артмаган һәм һәрберсе аерым бер гаилә өчен билгеләнгән, күрше блок белән яисә күрше блоклар белән уемнар булмаучы уртак дивары (уртак диварлары) булган берничә блоктан торучы, аерым җир кишәрлегендә урнашкан һәм гомуми файдаланудагы территориягә чыгу юлы булган торак йортлар (блоклап төзелгән торак йортлар);

3) өч каттан да артмаган, күләме дүрттән артмаучы һәм һәрберсендә берничә фатир һәм гомуми файдаланудагы бина һәм аларның һәркайсы гомуми файдаланудагы территориягә чыгу юлы белән аерым подъездга ия булган күпфатирлы йортлар;

4) РФ ШрК 48.1 статьясы нигезендә аеруча куркыныч, техник катлаулы яки уникаль объектлар булып саналган объектлардан гайре, ике каттан да артмаган, гомуми мәйданнары 1500 квадрат метрдан күбрәк булмаган һәм гражданнар яшәве һәм җитештерү эшчәнлеген башкару өчен каралмаган аерым торучы капиталь төзелеш объектлары;

5) ике каттан артмаган, гомуми мәйданнары 1500 квадрат метрдан да күбрәк булмаган, җитештерү эшчәнлеген башкаруга билгеләнгән һәм санитар-саклау зоналарын урнаштыру таләп ителмәгән яисә мондый объектлар урнашкан җир кишәрлекләре чигендә санитар-саклау зоналары урнаштырылган булса яисә мондый зоналарны урнаштыру таләп ителгән аерым торучы капиталь төзелеш объектлары, РФ ШрК 48.1 статьясы нигезендә куркыныч, техник катлаулы һәм уникаль объектлар булып саналучы объектлардан гайре.

Дәүләт төзелешен күзәтү Инспекция һәм аның территориаль органнары тарафыннан, РФ ШрК 52 статьясының 5 өлеше нигезендә, эшләр башлану турында хәбәрнамә алынган көннән башлап, төзелгән, үзгәртеп корылган капиталь төзелеш объектының техник регламентларның (нормаларның һәм кагыйдәләрнең), башка норматив-хокукый актларның һәм проект документларының таләпләренә, шул исәптән энергия нәтиҗәлелегенә кагылышлы таләпләргә һәм капиталь төзелеш объектының энергия ресурсларын исәпләү буенча кулланыла торган җайланмалар белән тәэмин ителешенә кагылышлы таләпләргә ярашуы турындагы бәяләмә (алга таба - ЯТБ) бирү көненә кадәр башкарыла.

1.5. Дәүләт төзелешен күзәтүнең предметы булып түбәндәгеләр санала:

1) капиталь төзелеш объектының төзелеше, үзгәртеп корылышы процессында башкарылган эшләрнең һәм кулланылган төзелеш материалларының, шулай ук мондый эшләрнең нәтиҗәләренең техник регламентлар, проект документлары, шул исәптән энергия нәтиҗәлелеге һәм капиталь төзелеш объектының энергия ресурсларын исәпләү буенча кулланыла торган җайланмалар белән тәэмин ителеше таләпләренә җавап бирүе;

2) төзелешкә рөхсәт кәгазенең булуы;

3) РФ ШрК 52 статьясының 2 һәм 3 өлешләрендәге таләпләрнең үтәлеше.

РФ ШрК 52 статьясының 2 өлеше нигезендә, капиталь төзелеш объектларының куркынычсызлыгына йогынты ясаучы капиталь ремонт объектларының төзелеше, үзгәртеп корылышы, капиталь төзекләндерелеше буенча эшләр бары тик үзен-үзе көйләүче оешма тарафыннан мондый эшләргә кертелү таныклыклары бирелгән шәхси эшмәкәрләр яисә юридик затлар тарафыннан гына башкарылырга тиеш.

РФ ШрК 52 статьясындагы 3 өлеше нигезендә, төзелешне башкаручы зат капиталь төзелеш объектын төзүне, үзгәртеп коруны, капиталь төзекләндерүне оештыра, әлеге эшләр барышында проект документларының, техник регламентларның, куркынычсызлык техникасының таләпләре саклануны тәэмин итә һәм башкарылган эшләрнең сыйфаты һәм аларның проект документларындагы таләпләргә ярашуы өчен җаваплылык тота. Төзелешне башкаручы зат, әлеге зат РФ ШрК 52 статьясындагы 2 өлешендә каралган таләпләргә җавап биргән очракта һәм (яки) әлеге таләпләргә туры килүче башка тиешле затларны җәлеп итү юлы белән, капиталь төзелеш объектының төзелеше, үзгәртеп корылышы, капиталь төзекләндерелеше барышында билгеле бер эшләр төрен мөстәкыйль башкарырга хокуклы.

Техник регламентлар булмаган очракта, башкарылган эшләрнең, кулланылган төзелеш материалларының һәм мондый эшләрнең нәтиҗәләренең төзелеш нормаларына һәм кагыйдәләренә, санитария-эпидемиология кагыйдәләренә һәм нормативларга, янгын куркынычсызлыгы таләпләренә, әйләнә-тирә мохитне саклау

өлкәсендәге таләпләргә, энергия нәтиҗәлелегенә кагылышлы таләпләргә һәм капиталь төзелеш объектының энергия ресурсларын исәпләү өчен кулланылучы җайланмалар белән тәэмин ителешенә кагылышлы таләпләргә, мәдәни мирас объектларын дәүләт саклавы таләпләренә һәм мәдәни мирас объектларын саклау таләпләренә, сәнәгать куркынычсызлыгы таләпләренә, гидротехник корылмаларның куркынычсызлыгы нормаларына һәм кагыйдәләренә, башка төр иминлек кагыйдәләренә һәм дәүләт стандартларына, шулай ук Россия Федерациясенең норматив-хокукый актларындагы башка таләпләргә һәм башкарма хакимият органнарының капиталь төзелеш объектының төзелеше, үзгәртеп корылышы барышында мәҗбүри башкарылырга тиешле норматив-хокукый актларына (алга таба – нормалар һәм кагыйдәләр) җавап бирүен күзәтү дәүләт төзелешен күзәтүнең предметы булып тора.

1.6. Инспекциянең вәкаләтле вазыйфаи затлары дәүләт төзелешен күзәтүне башкарганда түбәндәгеләргә хокуклы:

1.6.1. Хезмәт вазыйфаларын башкарганда капиталь төзелеш объектларына киртәләрсез үтеп керергә;

1.6.2. Заказчыдан, төзүчедән яисә подрядчыдан башкарылган эшләрнең нәтиҗәләрен, башкарма документларын, гомуми һәм (яки) махсус журналларны, эшләрне, конструкцияләрне, инженер-техник тәэмин ителеш челтәрләре урыннарын, кулланылучы төзелеш материалларының үрнәкләрен (пробаларын) таләп итәргә;

1.6.3. Төзелеш контролен башкарганда таләп ителсә, әмма башкарылмаган булса, техник заказчыдан, төзүчедән яисә подрядчыдан эшләнгән эшләргә һәм кулланылучы төзелеш материалларына карата тикшеренүләр, тәҗрибәләр, экспертизалар үткәрүне таләп итәргә;

1.6.4. Россия Федерациясенең административ хокук бозулар буенча законнарында каралган тәртиптә һәм очракларда административ хокук бозулар буенча беркетмәләр төзергә, административ хокук бозу эшләре буенча эш башкаруны тәэмин итү чараларын кулланырга.

1.7. Инспекциянең вәкаләтле вазыйфаи затлары дәүләт функциясен башкарганда түбәндәгеләрне тиеш:

1.7.1. Россия Федерациясе законнары нигезендә һичшиксез үтәлергә тиешле таләпләрне бозуны кисәтү, ачыклау һәм бетерү буенча билгеләнгән вәкаләтләрне үз вакытында һәм тулы күләмдә башкарырга.

1.7.2. Дәүләт функциясе башкарылучы затларга карата Россия Федерациясе законнарын, хокукларын һәм законлы ихтыяҗларын сакларга.

1.7.3. Инспекция башлыгы, башлык урынбасары яисә территориаль органы җитәкчесенең тикшерү үткәрү турындагы боерыгы нигезендә, аны максатына ярашлы итеп үткәрергә.

1.7.4. Тикшерүне бары тик хезмәт вазыйфаларын башкарганда гына, урынга чыгып үткәрелә торган тикшерүне бары тик хезмәт таныклыклары, Инспекция башлыгының, башлык урынбасарының яисә территориаль органы җитәкчесенең боерыгы күчермәсе һәм 294-ФЗ номерлы Федераль законның 10 статьясындагы 5 өлешендә каралган тикшерүне үткәрүнең прокуратура органнары белән килешенгәнлеге турындагы документның күчермәсе күрсәтелгән очракта гына үткәрергә;

1.7.5. Тикшерүне үткәргән вакытта җитәкче, башка вәкаләтле зат яисә юридик затның вәкаләтле вәкиле, шәхси эшмәкәр, аның вәкаләтле вәкиле катнашуына каршы килмәскә һәм тикшерү предметына кагылышлы мәсьәләләр буенча аңлатмалар бирергә.

1.7.6. Тикшерүне үткәргәндә катнашкан җитәкчегә, башка вәкаләтле затка яисә юридик затның башка вәкаләтле вәкиленә, шәхси эшмәкәргә, аның вәкаләтле вәкиленә тикшерүнең предметына кагылышлы мәгълүматны һәм документларны бирергә.

1.7.7. Җитәкчене, башка вәкаләтле затны яисә юридик затның вәкаләтле вәкилен, шәхси эшмәкәрне, аның вәкаләтле вәкилен тикшерү нәтиҗәләре белән таныштырырга.

1.7.8. Ачыкланган бозу фактларына карата кулланылучы чараларны билгеләгәндә, чараларның бозуларның катлаулылыгына туры килүенә, аларның кешеләрнең гомеренә, сәламәтлегенә, хайваннарга, үсемлекләргә, әйләнә-тирәлеккә, Россия Федерациясе милләтләренең мәдәни мирас объектларына (тарихи һәм мәдәни һәйкәлләренә), дәүләт иминлегенә, табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрнең килеп чыгышы өчен потенциаль куркынычлылыгын исәпкә алырга, шулай ук гражданнарның, шул исәптән шәхси эшмәкәрләрнең, юридик затларның хокукларын һәм законлы ихтыяҗларын урынсыз кысрыклауга юл куймаска;

1.7.9. Юридик затлар, шәхси эшмәкәрләр тарафын шикаять ителгәндә, үз эшләренең урынлы башкарылуын Россия Федерациясе законнарында каралган тәртиптә дәлилләргә;

1.7.10. Тикшерүне үткәрүнең тикшерү үткәрү турындагы боерыкта билгеләнгән вакытларын сакларга.

1.7.11. Юридик заттан, шәхси эшмәкәрдән Россия Федерациясенең законнарында каралмаган документларны һәм башка белешмәләрне таләп итмәскә.

1.7.12. Тикшерүне үткәрүне башлар алдыннан җитәкче, башка вәкаләтле зат, яисә юридик затның вәкаләтле заты, шәхси эшмәкәр, аның вәкаләтле заты соравы буенча аларны тикшерү үткәрүгә нигез бирүче Регламент кагыйдәләре белән таныштырырга;

1.7.13. Үткәрелгән тикшерүләрнең нәтиҗәләре буенча гомуми һәм (яисә) махсус журналга, капиталь төзелеш объектының төзелеше, үзгәртеп корылышы барышын исәптә тоту, күрсәтмәләр һәм ачыкланган бозуларны бетерү турында хәбәрнамәләр журналына язулар теркәргә.

1.7.14. Үзен-үзе көйләүче оешмаларның әгъзаларын планнан тыш урынга чыгып тикшергәндә, үзен-үзе көйләүче оешмага, планнан тыш урынга чыгып тикшерү барышында аның вәкиле катнашуны тәэмин итү максатларында, планнан тыш урынга чыгып тикшерү булачагы турында хәбәр итәргә.

1.8. үзләренә карата дәүләт төзелешен күзәтү башкарылучы юридик затлар һәм шәхси эшмәкәрләр, физик затлар түбәндәгеләргә хокуклы:

1.8.1. Тикшерү үткәрелгәндә турыдан-туры катнашырга, тикшерү предметына кагылышлы мәсьәләләргә аңлатмалар бирергә.

1.8.2. Инспекциянең тикшерү үткәрүче вазыйфаи затларыннан тикшерү предметына кагылышлы һәм аның бирелеше гамәлдәге законнарда каралган мәгълүматны алырга.

1.8.3. Тикшерү нәтиҗәләре белән танышырга һәм тикшерү актында тикшерү нәтиҗәләре белән танышканлыгын, алар белән, шулай ук Инспекциянең вазыйфаи затларының аерым эшләре белән килешүен яки килешмәвен күрсәтергә.

1.8.4. Россия Федерациясе законнары нигезендә тикшерү үткәргән вакытта Инспекциядәге вәкаләтле затларның юридик затның, шәхси эшмәкәрнең хокукларын бозуга китерүче эш-хәрәкәтләренә (гамьсезлегенә) шикаять бирергә.

1.9. Тикшерүне үткәргәндә юридик затлар һәм шәхси эшмәкәрләр түбәндәгеләрне тиешле:

1.9.1. Инспекциянең вазыйфаи затларын төзелеш мәйданына кертергә, тиешле документларны күрсәтергә:

- башкарылучы эшләрнең исәбе алып барылучы гомуми һәм (яисә) махсус журналларны.

- башкарма документларны, шул исәптән, куркынычсызлыкка йогынты ясаучы, аларның башкарылуын башка эшләрне башкарганнан соң, шулай ук төзелеш конструкцияләрен һәм инженер-техник тәэмин ителеш челтәрләре өлешләрен сүтмичә яисә зыян китермичә контрольдә тоту мөмкин булмаган эшләрне, конструкцияләрне, инженер-техник тәэмин ителеш челтәрләре өлешләрен карау актларын.

- төзелеш контролен үткәргәндә һәм дәүләт төзелешен күзәтүне тормышка ашырганда ачыкланган бозуларны бетерү турындагы актларны.

- төзелеш контроле процессында башкарылган эшләргә үткәрелгән экспертизалар, тикшеренүләр, лаборатор һәм башка төр тәҗрибәләрнең нәтиҗәләре.

- кулланылучы төзелеш материалларының сыйфатына карата контроль ясалуны дәлилләүче документлар.

- административ хокук бозулар буенча карарларның үтәлешен раслаучы документлар.

1.9.2. Тикшерүне үткәрүдән качмаска.

1.9.3. Тикшерүне үткәрү барышында килеп туган сораулар буенча аңлатмалар, мәгълүматлар бирергә.

1.9.4. Төзелеш контролен үткәрү һәм дәүләт төзелешен күзәтүне тормышка ашыру барышында ачыкланган бозуларны бетерергә һәм, мондый бозуларның бетерелүе турында актлар төзелгәнче, эшләрне дәвам иттермәскә.

1.9.5. Инспекциядәге вәкаләтле вазыйфаи затларының гамәлдәге законнарда каралучы үз вәкаләтләрен башкаруы өчен шартлар тудырырга.

1.9.6. РФ Икътисадый үсеш министрлыгының 30.04.2009 ел, 141 номерлы боерыгы белән расланган типлаштырылган формада үткәрелгән тикшерүләрнең исәп журналын алып барырга.

1.10. Дәүләт функциясен башкаруның нәтиҗәсе булып түбәндәгеләр санала:

1) РФ Икътисадый үсеш министрлыгының 30.04.2009 ел, 141 номерлы боерыгы белән расланган юридик затны, шәхси эшмәкәрне типлаштырылган форма буенча тикшерү акты; физик затны Ростехнадзорның 26.12.2006 ел, 1129 номерлы боерыгы белән расланган форма нигезендә тикшерү акты.

2) бозулар ачыкланганда:

Ростехнадзорның 26.12.2006 ел, 1129 номерлы боерыгы белән расланган форма нигезендә, аның башкарылу вакытын күрсәтеп, бозуларны бетерү буенча күрсәтмә.

Административ хокук бозу турындагы беркетмә (физик затка, вазыйфаи затка, юридик затка яисә шәхси эшмәкәргә карата).

Дәүләт төзелешен күзәтүне тормышка ашыру нәтиҗәләре буенча төзүчегә (техник заказчыга) ЯТБ бирелә яисә мондый бәяләмәне бирүдән баш тарту карары кабул ителә (алга таба – бәяләмә бирүдән баш тарту карары).

## 2. Дәүләт төзелешен күзәтүне тормышка ашыру тәртибенә карата таләпләр

2.1. Дәүләт төзелешен күзәтүне тормышка ашыру турында мәгълүматлаштыру тәртибе.

2.1.1. Инспекциянең урнашу урыны: 420111, Казан ш., З. Кызыл ур., 15/9 й..

2.1.2. Инспекциягә региональ дәүләт төзелешен күзәтүне тормышка ашыру мәсьәләләре буенча документлар һәм мөрәҗәгатьләр юллау өчен почта адресы: 420111, Казан ш., З. Кызыл ур., 15/9 й..

2.1.3. Инспекциянең эш графигы: дүшәмбе-пәнҗешәмбе 8.30 сәгатьтән 17.30 сәгатькә кадәр, җомга 08.30 сәгатьтән 16.30 сәгатькә кадәр, төшке аш - 12.00 сәгатьтән 12.45 сәгатькә кадәр, шимбә һәм якшәмбе – ял көннәре.

2.1.4. Белешмә телефоннары: 299-19-39, 299-78-18.

2.1.5. Инспекциянең территориаль органнары урнашкан урыннар:

| Территориаль орган | Адресы | Телефоны |
|---|---|---|
| Автоюллар һәм юл буе төзелешен күзәтү буенча территориаль орган | Казан ш., Декабристлар ур., 81Б | (843) 518-81-60 |
| Капиталь төзелеш объектының төзелешен, үзгәртеп корылышын күзәтү буенча өлкәара орган | Казан ш., Декабристлар ур, 81Б | (843) 518-83-44 |
| Капиталь төзелеш объектларының төзелешен, үзгәртеп корылышын күзәтү буенча Төньяк-Көнбатыш территориаль орган | Лаеш ш., Ульянова ур., 54 | (84378) 2-55-03 |
| Капиталь төзелеш объектларының төзелешен, үзгәртеп корылышын күзәтү буенча Төньяк-Көнчыгыш территориаль орган | Чаллы ш., Госманов ур., 57а | (8552) 52-74-52 |
| Капиталь төзелеш объектларының төзелешен, үзгәртеп корылышын күзәтү буенча Көнчыгыш территориаль орган | Түбән Кама ш., Б. Урманче ур, 24 й. | (8555) 30-15-31 |

| | | |
|---|---|---|
| Капиталь төзелеш объектларының төзелешен, үзгәртеп корылышын күзәтү буенча Кама арты территориаль орган | Чистай ш., Толстой ур., 157 | (84342) 5-45-69 |
| Капиталь төзелеш объектларының төзелешен, үзгәртеп корылышын күзәтү буенча Көньяк-Көнчыгыш территориаль орган | Әлмәт ш., Шевченко ур., 62 | (8553) 45-80-83 |
| Капиталь төзелеш объектларының төзелешен, үзгәртеп корылышын күзәтү буенча Көнбатыш территориаль орган | Яшел Үзән ш., Норкин ур., 6 | 8 (84371) 47095 |
| Экспертизалар, тикшеренүләр һәм тәҗрибәләр үткәрүне күзәтү буенча территориаль орган | Казан ш., Декабристлар ур., 81Б | (843) 518-81-60 |

2.1.6. Инспекциянең “Интернет” челтәрендәге рәсми сайты: htpp://gsn.tatarstan.ru. Электрон почта адресы: gsn@tatar.ru.

2.1.7. Дәүләт төзелешен күзәтүне тормышка ашыру мәсьәләләре буенча мәгълүмат түбәндәгечә җиткерелә:

Телдән мөрәҗәгать буенча (шәхси яисә телефон аша);

Язмача мөрәҗәгать буенча;

Электрон почтадан алынган мөрәҗәгать буенча;

Инспекциянең рәсми интернет-сайтында урнаштыру юлы белән;

Инспекция һәм аның территориаль органнары биналарындагы мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән.

Телдән мөрәҗәгатькә җавап мөрәҗәгать иткәннән соң озакка сузмыйча бирелә, язмача һәм (яисә) электрон почта аша җибәрелгән мөрәҗәгатькә җавап, мондый мөрәҗәгатьнең Инспекциядә теркәлгән көненнән башлап 30 көннән дә артмаган срокта, юридик затның, шәхси эшмәкәрнең, физик затның почта адресына, яисә электрон почтасына җибәрелә.

Инспекциянең яисә аның территориаль органнарының шалтыратуны кабул иткән вазыйфаи заты куелган сорауларга җавап бирә алмаса, телефоннан сөйләшү башка вазыйфаи затка адреслана (тапшырыла) яисә мөрәҗәгать итүчегә кирәкле мәгълүматны алырга мөмкин булган телефон номеры әйтелә.

2.1.8. Инспекциянең мәгълүмат стендларында һәм http://gsn.tatarstan.ru рәсми интернет-сайтында түбәндәге мәгълүмати материаллар урнаштырыла:

дәүләт төзелешен күзәтүнең тәртибе турындагы мәгълүмат;

дәүләт төзелешен күзәтүне башкаруны көйләүче норматив-хокукый актлардан күчермәләр;

тутыру өчен документларның формалары.

Инспекциянең урнашу урыны, эш графигы, телефоннар һәм факс номеры, электрон почта адресы;

дәүләт функциясен үтәү барышында тормышка ашырылучы эшләргә (гамьсезлеккә) һәм карарларга карата шикаять бирү тәртибе;

дәүләт функциясен үтәгәндә эшләрнең эзлеклелеген чагылдыручы блок-схема.

2.2. Региональ дәүләт төзелешен күзәтү буенча чаралар үткәрүгә, шул исәптән, экспертларның һәм эксперт оешмаларының хезмәтләренә, тикшерү үткәрүгә аларны җәлеп иткән очракта, юридик затлардан һәм шәхси эшмәкәрләрдән түләү алынмый.

2.3. Бер юридик затка яисә шәхси эшмәкәргә карата тикшерү үткәрү вакыты егерме эш көненнән артып китә алмый.

Урынга чыгып планлы тикшерү үткәрү, Инспекция һәм аның территориаль органнарындагы вазыйфаи затларның нигезләнгән тәкъдимнәре буенча катлаулы һәм (яисә) озак тикшеренүләрне, тәҗрибәләрне, махсус экспертизаларны һәм тикшерүләрне үткәрергә кирәк булган аерым очракларда, урынга чыгып тикшерү үткәрүнең вакыты Инспекциянең башлыгы һәм территориаль органнарның җитәкчеләре тарафыннан егерме көннән дә артмаган вакытка кадәр озайтылырга мөмкин.

2.4. Тикшерүләрне үткәрүнең сәбәбе.

Юридик затларга һәм шәхси эшмәкәрләргә түбәндәге сәбәпләр буенча тикшерү үткәрелә:

2.4.1. тикшерүләр Инспекциягә юлланган түбәндәгеләр нигезендә үткәрелә:

2.4.1.1. төзүчедән (техник заказчыдан) яисә төзүне башкаручы заттан РФ ШрК 52 статьясының 5 һәм 6 өлешләре нигезендә төзелешнең тәмамлануы турында юлланган хәбәрнамә;

2.4.1.2. гражданнарның, шул исәптән шәхси эшмәкәрләрнең, юридик затларның мөрәҗәгатьләре һәм гаризалары, РФ ШрК 53 статьясының 3 өлеше нигезендә төзелеш башкаручы затлардан юллanучы хәбәрнамәләрне дә кертеп, дәүләт хакимияте органнарыннан (дәүләт күзәтчелеге органнарының вазыйфаи затларыннан), җирле үзидарә органнарыннан кергән мәгълүмат, РФ ШрК 53 статьясының 3 өлеше нигезендә төзүне башкаручы затлардан юллanучы хәбәрнамәләрне дә кертеп, капиталь төзелеш объектының төзелеше, үзгәртеп корылышы процессында эшләрне башкарганда килеп чыккан аварияләр, техник регламентларның, башка норматив-хокукый актларның һәм проект документларының, шул исәптән, әгәр дә мондый бозулар кешенең тормышына, сәламәтлегенә, әйләнә-тирә мохиткә, дәүләтнең иминлегенә, физик һәм юридик затларның мөлкәтенә, дәүләти һәм муниципаль мөлкәткә куркыныч тудырса яисә мондый зыян салынуга китерсә, кулланылучы төзелеш материалларына карата һичшиксез үтәлергә тиешле таләпләрнең бозылуы турындагы фактлар буенча, массакүләм мәгълүмат чараларыннан алынган мәгълүмат. Әлеге тикшерү Инспекция тарафыннан, 294-ФЗ номерлы Федераль законның 10 статьясының 12 өлешендә каралган тәртиптә, прокуратура органына хәбәр итү белән берлектә,

кичекмәстән егерме дүрт сәгать эчендә түбәндәге документларны юллау юлы белән үткәрелә: дәүләт күзәтчелеге органының юридик затка, шәхси эшмәкәргә карата урынга чыгып планнан тыш тикшерү үткәрүенең прокуратура органы белән килешенгәнлеге турындагы гариза; Инспекция башлыгының, башлык урынбасарының, Инспекциянең территориаль органы җитәкчесенең планнан тыш тикшерүне үткәрү турындагы әмернамәсенең күчермәсе; планнан тыш тикшерүне үткәрүгә сәбәп булган мәгълүматларны үз эченә алган документлар.

2.4.2. Инспекция тарафыннан эшләнгән тикшерүләр программасы буенча;

2.4.3. Юридик затларга, шәхси эшмәкәрләргә мәҗбүри таләпләрнең ачыкланган бозуларын бетерү турында Инспекция биргән күрсәтмәнең вакыты бетү;

2.4.4. Инспекция башлыгының (башлык урынбасарларының) Россия Федерациясе Президенты яисә Россия Федерациясе Хөкүмәте кушуы буенча чыгарылган боерыкның (әмернамәнең) булуы яисә прокуратура органнарына килгән материаллар һәм мөрәҗәгатьләрнең үтәлешен күзәтү кысаларында прокурорның планнан тыш тикшерү үткәрүне таләп итүе нигезендә.

Дәүләт төзелешен күзәтү органының вазыйфаи заты тарафыннан физик затларны тикшерүләр түбәндәге сәбәпләр буенча тормышка ашырыла:

а) башкарылган эшләрнең тикшерүләрне үткәрү программасы нигезендә тикшерүгә тиешле вакытлары җитү;

б) төзүне башкаручы заттан тикшерелергә тиешле эшләрнең тәмамлануы турында хәбәрнамә алу, әгәр дә мондый эшләрнең тәмамлану вакыты тикшерү үткәрү программасында каралган вакытлар белән тәңгәл килмәсә;

в) төзүне башкаручы заттан капиталь төзелеш объектында авария хәлләре барлыкка килү очраклары турында хәбәрнамә алу;

г) дәүләт төзелешен күзәтүне тормышка ашыруга кагылышлы мәсьәләләр буенча физик затлардан һәм юридик затлардан, дәүләт хакимияте органнарыннан һәм җирле үзидарә органнарыннан мөрәҗәгатьләр килү;

д) башка чыганаклардан капиталь төзелеш объектының төзелеше, үзгәртеп корылышы, капиталь төзекләндерелеше буенча тикшерергә тиешле эшләрнең башкарылуы турындагы мәгълүматлар алыну.

2.5. Дәүләт төзелешен күзәтүне турыдан-туры дәүләт төзелешен күзәтү органы әмернамәсе (боерыгы) нигезендә һәм аның исеменнән мондый күзәтүне башкаруга вәкаләт бирелгән дәүләт төзелешен күзәтү органының вазыйфаи затлары башкара.

2.6. 294-ФЗ номерлы Федераль закон бозылуга юл куйган, тикшерүләрне үткәрүгә нигезсез каршылык күрсәтүче, тикшерүләрне үткәрүдән качып йөрүче һәм (яки) мәҗбүри таләпләрдә ачыкланган бозуларны бетерү буенча Инспекция күрсәтмәләрен билгеләнгән вакытка үтәмәүче юридик затлар, аларның җитәкчеләре, башка вазыйфаи затлар яисә юридик затларның вәкаләтле вәкилләре, шәхси эшмәкәрләр, аларның вәкаләтле вәкилләре Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплылыкка тартыла.

2.7. Тикшерү үткәргәндә Инспекциянең һәм аның территориаль органнарының вазыйфаи затларының җаваплылыгы.

2.7.1. Инспекциянең һәм аның территориаль органнарының тиешле функцияләрне, хезмәт вазыйфаларын тиешенчә башкармаган, хокуксыз кылынган (гамьсез булган) вазыйфаи затлары Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплылык тота.

2.7.2. Инспекция һәм аның территориаль органнары вазыйфаи затларның хезмәт вазыйфаларын башкаруын контрольдә тота, вазыйфаи затларның хезмәт вазыйфаларын тиешенчә башкармаган очракларының исәбен алып бара, тиешле хезмәт тикшерүләре алып бара һәм Россия Федерация законнары нигезендә мондый вазыйфаи затларга карата чаралар күрә.

2.7.3. Россия Федерациясе законнарын бозучыларга күрелгән чаралар турында, мондый чаралар кабул ителгән көннән ун көн эчендә, хокуклары һәм (яки) законлы ихтыяҗлары бозылган юридик затка, шәхси эшмәкәргә, физик затка язмача формада хәбәр ителә.

## 3. Юридик затларга, шәхси эшмәкәрләргә куелган мәҗбүри таләпләр.

Башкарылышы аларны билгеләүче норматив-хокукый актлар белән контрольдә тотылучы, юридик затларга, шәхси эшмәкәрләргә карата билгеләнгән мәҗбүри таләпләрнең исемлеге, юридик затлардан, шәхси эшмәкәрләрдән тикшерү барышында күрсәтелергә тиешле документлар исемлеге 1 нче таблицада күрсәтелгән.

1 нче таблица – Юридик затларга һәм шәхси эшмәкәрләргә куелган мәҗбүри таләпләрнең исемлеге

| **Контрольдә тотылучы объектлар (эшчәнлек төрләре, контрольлек итү төрләре)** | **Мәҗбүри таләпнең тәгъбирләнеше** | **Мәҗбүри таләпне билгеләүче норматив-хокукый акт** |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| Проект документлары РФ ШрК 49 статьясы нигезендә экспертизага тиешле яисә типлаштырылган проект документлары яисә аның модификациясе булган капиталь төзелеш объектлары төзелешен дәүләт төзелешен күзәтү; | Капиталь төзелеш объектының төзелеше, үзгәртеп корылышы буенча эшләрне координацияләү, проект документларының, техник регламентлардагы таләпләренең, әлеге эшләр барышында куркынычсызлык техникасының үтәлеше һәм аларның проект документлары таләпләренә туры килүе һәм башкарылган эшләрнең сыйфаты өчен җаваплылык.<br><br>Җир кишәрлеген төзүгә һәм капиталь төзелеш объектын үзгәртеп коруга әзерләү, шулай ук төзүне башкаручы затка инженер эзләнүләре материалларын, проект документларын, төзелешкә рөхсәт тапшыру. | Россия Федерациясенең Шәһәр төзелеше кодексы;<br>Россия Федерациясендә дәүләт төзелешен күзәтүне башкару турында Нигезләмә (2006 ел,1 февраль, 54 номерлы РФ Хөкүмәте карары белән расланган);<br><br>“Дәүләт төзелешен күзәтүне тормышка ашырганда һәм төзелгән, үзгәртеп корылган, төзекләндерелгән капиталь төзелеш объектларының техник регламентларның (нормаларның һәм кагыйдәләрнең), башка норматив-хокукый актларның һәм ЖД-11-04-2006 проект документларының таләпләренә туры килүен тикшерү тәртибе” (Экологик, технологик һәм атом күзәтчелеге федераль хезмәтенең 2006 ел, 26 декабрь, 1129 номерлы боерыгы белән расланган)<br><br>Милли стандартлар |

| | | |
|---|---|---|
| Әгәр капиталь төзелеш объектын үзгәртүп коруга проект документлары РФ ШрК 49 статьясы нигезендә экспертизага тиешле булса, капиталь төзелеш объектларының үзгәртеп корылышын дәүләт төзелешен күзәтү. | Эшләрне алты айдан да артыграк вакытка өзү яисә аларны туктатып тору кирәк булганда төзүче яисә техник заказчы капиталь төзелеш объектының консервацияләнүен тәэмин итәргә тиеш.<br><br>Капиталь төзелеш объекты төзелешен, үзгәртеп корылышын төзүче яисә техник заказчы (төзү, үзгәртеп кору эшләре килешү нигезендә башкарылганда) биреме буенча, проект документларын, җир кишәрлегенең шәһәр төзелеше планы таләпләрен, техник регламент таләпләре нигезендә башкаруны һәм шул ук вакытта өченче затлар һәм әйләнә-тирәлек өчен куркынычсызлыгын, хезмәт иминлеген, мәдәни мирас объектларын саклауны тәэмин итү.<br><br>Төзүне башкаручы зат шулай ук төзүчене яисә техник заказчыны, дәүләт төзелешен күзәтү органнарын капиталь төзелеш объектының төзелеше, үзгәртеп корылышы алып барылган территориягә кертүне | 1. ГОСТ 27751-88 “Төзелеш конструкцияләренең һәм нигезләренең ышанычлылыгы”.<br>2. ГОСТ 25100-95 “Грунтлар. Классификациясе”. 3-5 бүлекләр; А кушымтасы.<br>3. ГОСТ 30494-96 “Торак һәм җәмәгать биналары. Биналардагы микроклиматның параметрлары”. 3 бүлек.<br>4. ГОСТ Р 51164-98 “Корыч магистраль торбаүткәргечләр. Тутыгуга каршы гомуми таләпләр”.<br>5. ГОСТ Р 22.1.12-2005 “Гадәттән тыш хәлләрдә куркынычсызлык. Мониторингның һәм биналарның һәм корылмаларның инженерлык системалары белән идарә итүнең структуралаштырылган системасы. Гомуми таләпләр”.<br>6. ГОСТ Р 52748-2007 “Гомуми кулланылыштагы автомобиль юллары. Норматив йөкләнешләр, йөкләүнең исәп схемалары һәм якын килүнең габаритлары”. 4,5 бүлекләр.<br>7. ГОСТ 21.1101-2009 “СПДС. Проект һәм эш документларына карата төп таләпләр”.<br>8. ГОСТ Р 53778-2010 “Биналар һәм корылмалар. Техник торышны тикшерү һәм мониторинглау кагыйдәләре”.<br><br>Кагыйдәләр җыелмасы<br><br>9. СНиП II-58-75 “Җылылык электр станцияләре”. 1 нче ( 1.1, 1.3 пунктлар), 2 нче (2.1-2.19, 2.24-2.42 пунктлар), 3 нче ( 3.1-3.9, 3.12, 3.13 пунктлар), 4 нче (4.1-4.24, 4.26-4.54, 4.56, 4.58-4.60, 4.62-4.68, 4.70, 4.76, 4.79-4.83 пунктлар), 5 нче, 6 нчы ( 6.1-6.47, 6.58-6.62 пунктлар), 7 нче |

| | | |
|---|---|---|
| | тәэмин итәргә, аларга кирәкле документларны бирергә, төзелеш контролен башкарырга, башкарма документларның алып барылышын тәэмин итәргә, эшләрне тәмамлауның тикшерүгә тиешле вакытлары турында төзүчегә яисә техник заказчыга, дәүләт төзелешен күзәтү органнары вәкилләренә хәбәр биреп торырга, ачыкланган кимчелекләрне бетерергә һәм, ачыкланган кимчелекләрне бетерү турында актлар төзелгәнчегә кадәр, эшләрне дәвам иттермәскә, кулланылучы төзелеш материалларының сыйфатына контроль булуны тәэмин итәргә бурычлы.<br><br>Капиталь төзелеш объектының төзелеше, үзгәртеп корылышы барышында башкарылучы эшләрнең, кулланылучы төзелеш материалларының һәм мондый эш нәтиҗәләренең техник регламентларның, нормаларның һәм кагыйдәләрнең, шулай ук башка норматив-хокукый актларның һәм проект | бүлекләр.<br>10. СНиП II-26-76 “Түбәләр”. 1 нче, 2 нче бүлекләр (2.1-2.22, 2.24-2.26, 2.28 пунктлар), 3-5 нче бүлекләр.<br>11. СНиП II-35-76 “Пар казаннары бинасы җайланмалары”. 1 нче (1.1-1.22* пунктлар), 2 нче (пунктының беренче, икенче, дүртенче-алтынчы абзацлары, 2.5, 2.6, 2.8-2.13 пунктлар), 3 нче (3.2-3.8, 3.12-3.15*, 3.17-3.30 пунктлар), 4-7 нче, 10 нчы, 14-16 нчы, 17 нче (17.1-17.4, 17.11-17.22* пунктлар) бүлекләр.<br>12. СНиП II-97-76 “Авыл хуҗалыгы предприятиеләренең генераль планнары”. 1 нче, 2 нче, 3 нче (3.1-3.19, 3.21-3.23, 3.25 пунктлар), 4 нче (4.1-4.4, 4.6-4.12, 4.17 пунктлар), 5 нче, 6 нчы бүлекләр.<br>13. СНиП II-108-78 “Коры минераль ашламалар һәм үсемлекләрне саклауның химик чаралары складлары”. 1 нче (пунктлар 1.1, 1.3-1.10), 2 нче (пунктлар 2.1, 2.2, 2.5), 3 нче (пунктлар 3.1-3.4, 3.6-3.9, 3.11-3.16, 3.18-3.25), 4 нче (пунктлар 4.1, 4.2, 4.4-4.7), 5 нче, 6 нчы (пунктлар 6.1, 6.2, 6.4-6.6) бүлекләр.<br>14. СНиП II-25-80 “Агач корылмалар”.<br>15. СНиП III-42-80* “Магистраль торбаүткәргечләр”. 4-6 нчы, 9 нчы, 11 нче, 13 нче бүлекләр.<br>16. СНиП II-89-80* “Сәнәгать предприятиеләренең генераль планнары”. 2 нче, 3 нче (пунктлар 3.1*, 3.3*-3.31, 3.38-3.42, 3.45, 3.48-3.51, 3.53-3.59, 3.62, 3.63, 3.65-3.86 пунктлар), 4 нче (4.1, 4.4, 4.7-4.9 пунктлар, 4.11* пунктының беренче абзацы, 4.12-4.14, 4.16-4.18, 4.20-4.22, 4.26, 4.27* пунктлар) бүлекләр.<br>17. СНиП II-94-80 “Җир асты казылма табу урыннары”. 1-4 нче, 5 нче (5.1-5.47, 5.50, 5.55-5.69 пунктлар) бүлекләр. |

| | | |
|---|---|---|
| | документларының таләпләренә туры килүен тикшерүгә түбәндәгеләрне үтәү тиешле:<br>а) төзелеш барышында – җир кишәрлеген әзерләүгә һәм җир эшләрен башкаруга фундаментларының, җир асты һәм җир өсте өлеше конструкцияләренең, инженер-техник тәэмин ителеш челтәрләре (шул исәптән эчке һәм тышкы челтәрләр), инженерлык челтәрләрен һәм җайланмаларын монтажлау буенча эшләрне башкаруга карата таләпләрне;<br>б) үзгәртеп корганда – капиталь төзелеш объектының, аның өлешләренең параметрларын үзгәрткән, шулай ук капиталь төзелеш объектының тотып торучы төзелеш конструкцияләрен алмаштырган һәм (яки) киредән торгызган очракта (мондый конструкцияләрнең аерым элементларын аналог яисә мондый конструкцияләрнең күрсәткечләрен яхшыртучы башка элементларга алмаштыру һәм (яки) күрсәтелгән элементларны торгызудан гайре), шулай ук чик | 18. СНиП II-7-81* “Сәйсмик районнардагы төзелеш. Проектлау нормалары”. 1 нче, 2 нче бүлекләр.<br>19. СНиП II-22-81* “Таш һәм армоташ конструкцияләр”. 1-6 бүлекләр.<br>20. СНиП II-23-81* “Корыч конструкцияләр”.<br>21. СНиП 2.06.04-82* “Гидротехник корылмаларга йөкләнешләр һәм йогынтылар (дулкынлы, бозлы һәм суднолардан)”. 1-5 нче бүлекләр.<br>22. СНиП 2.02.01-83* “Биналарның һәм корылмаларның нигезләре”. 1 нче, 2 нче ( 2.2-2.9, 2.12-2.18, 2.22-2.24, 2.29-2.34, 2.39-2.53, 2.57-2.65, 2.67 пунктлар), 3 нче (пунктлар 3.4, 3.5, 3.8, 3.9, 3.12-3.14), 4 нче ( 4.5, 4.6 пунктлар), 5 нче ( 5.2-5.5 пунктлар), 6 нчы ( 6.4, 6.5 пунктлар), 7 нче ( 7.3-7.6 пунктлар), 8 нче ( 8.4, 8.5 пунктлар), 9 нчы, 10 нчы (10.2-10.7 пунктлар ), 11 нче ( 11.2-11.9 пунктлар), 12 нче ( 12.3-12.8 пунктлар), 13 нче (13.3-13.8 пунктлар ), 14 ( 14.4-14.8 пунктлар), 15 нче ( 15.4-15.7 пунктлар), 16 нчы ( 16.3-16.10 пунктлар), 17 нче (17.3-17.14 пунктлар ), 18 нче ( 18.2-18.18 пунктлар) бүлекләр; 2 нче кушымта.<br>23. СНиП 2.03.04-84 “Күтәренке һәм югары температуралар йогынтысы шартларында эшләү өчен билгеләнгән бетон һәм тимербетон конструкцияләр”. 1-5 нче бүлекләр.<br>24. СНиП 2.04.02-84* “Су белән тәэмин итү. Тышкы челтәрләр һәм корылмалар”. 2 нче ( 2.1-2.10, 2.26-2.28 пунктлар), 4 нче, 6 нчы, 7 нче (7.1-7.17, 7.19-7.22 пунктлар), 8 нче (8.1-8.15, 8.17-8.66 пунктлар ), 9 нчы ( 9.1, 9.2, 9.6-9.19, 9.21-9.26 пунктлар), 10 нчы, 12 нче, 13 нче ( 13.1-13.20, 13.22-13.55 пунктлар), 15 нче ( 15.1, 15.2, 15.5, 15.7-15.81, 15.83-15.131* пунктлар) бүлекләр. |

| | | |
|---|---|---|
5.2.1. Теркәү һәм документ әйләнешен алып баруга җаваплы булган вазыйфаи зат Инспекциягә (территориаль органнарга) кергән капиталь төзелеш объектының төзелеше, үзгәртеп корылышы башлануы турындагы хәбәрнамәне һәм Регламентның 2.4.1.1. пунктында күрсәтелгән документларны (алга таба – эшләрнең башлануы турындагы хәбәрнамә (7 нче номерлы Кушымта)) “Электрон Хөкүмәт” системасында һәм “ТР Төзелеш күзәтчелеге” ЭИСында терки һәм эшләрнең башлануы турындагы хәбәрнамәне дәүләт төзелешен күзәтүне тормышка ашырганда рәсмиләштерелүче документларны кабул итүгә җаваплы булган вазыйфаи затка (алга таба – документларны кабул итүче вазыйфаи зат) тапшыра.

Башкару вакыты: кабул итү көненнән башлап бер көн дәвамында.

Эшнең нәтиҗәсе: документларны кабул итүче вазыйфаи затка тапшырылган “Электрон Хөкүмәт” системасында һәм “ТР Дәүләт күзәтчелеге” ЭИСында теркәлгән эшләрнең башлануы турындагы хәбәрнамә.

5.2.2. Документларны кабул итүче вазыйфаи зат:

эшләрнең башлануы турындагы хәбәрнамәнең дөрес тутырылышын һәм Регламентның 2.4.1.1 пунктында күрсәтелгән документларның барлыгын тикшерә;

тикшерелгән эшләрнең башлануы турындагы хәбәрнамәне, беркетелгән документлары белән берлектә, территориаль орган җитәкчесенә яисә аның урынбасарына объектка дәүләт төзелешен күзәтүне тормышка ашыру өчен вазыйфаи затларны билгеләү, әлеге объектта күзәтүне башкаруга җаваплы булган вазыйфаи затны билгеләү турындагы карарны кабул итү, аларның билгеләнүе турындагы боерыкны (әмернамәне) рәсмиләштерү өчен тапшыра.

Эшләрнең башлануы турындагы хәбәрнамә ярашлы булмаганда һәм Регламентның 2.4.1.1 пунктында күрсәтелгән документларның тулы пакеты булмаган очракта, документларны кабул итүче вазыйфаи зат төзүчегә яисә техник заказчыга тапшырылган документларда җитешсезлекләр булуы хакында аңлатмалы хат юллый.

Башкару вакыты: алдагы процедураның тәмамлану вакытыннан алып бер эш көне дәвамында.

Эшнең нәтиҗәсе: төзүче яисә техник заказчы исеменә җибәрелгән аңлатмалы хат яисә территориаль орган җитәкчесенә яисә аның урынбасарына теркәлгән документлары белән берлектә юлланган эшләрнең башлануы турындагы хәбәрнамә.

5.3. “Дәүләт төзелешен күзәтүне тормышка ашыруга әзерләнү” административ процедурасы.

5.3.1. Территориаль орган җитәкчесе яисә аның урынбасары, документларны кабул итүче вазыйфаи заттан теркәлгән документлары белән берлектә эшләрнең башлануы турындагы хәбәрнамәне алганнан соң, объектта дәүләт төзелешен күзәтүне тормышка ашыру өчен вазыйфаи затларны билгеләү, шул исәптән күзәтүне тормышка ашыру өчен җаваплы вазыйфаи затны билгеләү турында карар кабул итә, аларның билгеләнүе турындагы боерыкны (әмернамәне) рәсмиләштерү һәм объектта күзәтүне тормышка ашыруга җаваплы булган вазыйфаи затка территориаль орган җитәкчесенең яисә аның урынбасарының боерыгы проектын әзерләүне йөкли.

Башкару вакыты: алдагы процедураның тәмамлану вакытыннан алып бер эш көне дәвамында.

Эшнең нәтиҗәсе: объектта күзәтүне башкаруга җаваплы булган вазыйфаи затка территориаль орган җитәкчесенең дәүләт төзелешен күзәтүне тормышка ашыру өчен вазыйфаи затларны билгеләү турындагы боерыгы проектын әзерләүне йөкләү.

5.3.2. Объектта күзәтүне тормышка ашыруга җаваплы булган вазыйфаи зат 8 нче номерлы Кушымта нигезендә объектта дәүләт төзелешен күзәтүне тормышка ашыруга җаваплы булган вазыйфаи затларны һәм вазыйфаи затны билгеләү турындагы боерыкның проектын әзерли, аны территориаль орган җитәкчесенә имзалар өчен тапшыра. Территориаль орган җитәкчесе әлеге боерыкны карый һәм имзалый.

Башкару вакыты: алдагы процедураның тәмамлану вакытыннан алып бер эш көне дәвамында.

Эшнең нәтиҗәсе: вазыйфаи затларның һәм объектта дәүләт төзелешен күзәтүне тормышка ашыру өчен җаваплы вазыйфаи затның билгеләнүе турындагы боерык.

Объектта күзәтүне тормышка ашыруга җаваплы вазыйфаи зат эшне рәсмиләштерү (кәгазьдә генә түгел, ә "ТР Төзелеш күзәтчелеге" ЭИСында да) өчен, объектта тикшерүләр үткәргәндә дәүләт төзелешен күзәтүне тормышка ашыру өчен җаваплы.

5.3.3. Төзелеш, үзгәртеп корылыш объектында күзәтчелек эшчәнлеген планлаштыруны тәэмин итү өчен объектта күзәтүне тормышка ашыру өчен җаваплы булган вазыйфаи зат тарафыннан капиталь төзелеш объектының конструктив һәм башка үзенчәлекләрен һәм аның төзелеше, үзгәртеп корылышы буенча эшләрнең башкарылышын, киләчәктәге эксплуатация шартларын, шулай ук техник регламентларның (нормаларның һәм кагыйдәләрнең), башка төр норматив-хокукый актларның һәм проект документларының таләпләре нигезендә исәптә тотылырга тиешле башка факторларны да исәпкә алып, Тикшерүләрне үткәрүнең программасы (алга таба - Программа) эшләнә (9 нчы номерлы Кушымта).

Башкару вакыты: Инспекция (территориаль органнары тарафыннан) эшләрнең башлануы турындагы хәбәрнамәне алу көненнән алып 7 эш көне дәвамында.

Эшнең нәтиҗәсе: эшләнгән Программа.

Программада түбәндәге белешмәләр күрсәтелә:

а) капиталь төзелеш объектының төзелешен оештырганда РФ ШрК 48 статьясының 12 нче өлешендәге 6 нчы пунктта каралган проект нигезендә билгеләнүче тикшерелергә тиешле эшләрнең исемлеге (алга таба – капиталь төзелеш объектының төзелешен оештыру проекты);

б) үткәреләчәк һәр тикшерүнең предметы;

в) үткәреләчәк һәр тикшерүнең капиталь төзелеш объектының төзелешен оештыру проекты күрсәткечләре нигезендә ачыкланган якынча көне;

г) дәүләт төзелешен күзәтү органындагы вазыйфаи затның үткәреләчәк һәр тикшерүгә чама белән сарыф ителәчәк вакыты;

д) дәүләт төзелешен күзәтү органындагы вазыйфаи зат тарафыннан тикшерүләрне үткәрү өчен кирәкле булган башка белешмәләр.

Программа 2 нөсхәдә төзелә, алар арасыннан беренчесе дәүләт төзелешен күзәтү органындагы эш документларында кала, икенчесе – төзүчегә яисә техник заказчыгы юллана (тапшырыла).

Программаның икенче нөсхәсе техник заказчының яисә төзүченең вәкаләтле затына вәкиллек турындагы тиешле документ нигезендә тапшырыла. Төзүченең яисә техник заказчының вәкиле программаның нөсхәсен кулга алудан (имзалаудан) баш тарткан очракта, документ заказлы хат итеп, почта аша белдермәнамә белән җибәрелә.

Төзүче яисә техник заказчы төзүне башкаручы затка Программада каралган тикшерүләр турындагы белешмәләрне җиткерергә бурычлы.

Төзүне башкаручы зат, 1 нче номерлы Кушымта нигезендә, Программада күрсәтелгән эшләрнең тәмамлану вакытларының үзгәрүе турында Инспекциягә хәбәр итәргә бурычлы

5.4. “Хокук бозулар ачыкланганда тикшерүләрне тиешле административ чараларны кулланып тормышка ашыру” административ процедурасы.

5.4.1. Әлеге объектта күзәтүне тормышка ашыруга җаваплы булган вазыйфаи зат Инспекция башлыгының, аның урынбасарының, территориаль органы җитәкчесенең тикшерүне үткәрү турындагы әмернамәсе (алга таба – тикшерүне үткәрү турындагы әмернамә) (12 нче номерлы Кушымта) проектын әзерли, аны Инспекциянең территориаль органы җитәкчесенә имза кую өчен тапшыра.

Башкару вакыты: тикшерүне үткәрүгә өч эш көненнән дә соңармыйча.

Эшнең нәтиҗәсе: Инспекциянең территориаль органы җитәкчесе тарафыннан имзаланган тикшерү үткәрү турындагы әмернамә.

5.4.2. Тикшерү башланыр алдыннан дәүләт төзелешен күзәтү органының вазыйфаи заты төзүчегә (техник заказчыга) тикшерү үткәрелү турында телефон, факсимиль яисә электрон элемтә аша хәбәр итә. Белдермәнамәдә тикшерүне үткәрүнең көне, тикшерүнең предметы, тикшерүне үткәрү өчен кирәкле булган башка белешмәләр күрсәтелә (13 нче номерлы Кушымта). Белдермәнамә төзүченең яисә техник заказчының вәкаләтле вәкиленә вәкиллек турындагы тиешле документ нигезендә тапшырыла. Төзүченең яисә техник заказчының вәкиле белдермәнамәне кулга алудан (имзалаудан) баш тартканда, документ факс аша яисә почта аша заказлы хат итеп белдермәнамә белән юллана.

Башкару вакыты: тикшерүне үткәрүгә өч эш көненнән дә соңармыйча.

Эшнең нәтиҗәсе: юридик зат, шәхси эшмәкәр, физик зат адресына юлланган тикшерүне үткәрү турындагы белдермәнамә.

5.4.3. Инспекция башлыгы (башлык урынбасарлары) яисә территориаль органы җитәкчесе әмернамәсенең мөһер белән рәсмиләштерелгән күчермәсе Инспекциянең тикшерүне үткәрүче вазыйфаи затының имзасы белән җитәкчегә, башка вазыйфаи затка яисә юридик затның вәкаләтле вәкиленә, шәхси эшмәкәргә, аның вәкаләтле вәкиленә бер үк вакытта хезмәт таныклыкларын күрсәтеп тапшырыла. Тикшерүгә тиешле затларның таләбе буенча Инспекциянең вазыйфаи затлары, үзләренең вәкаләтләрен раслау максатларында, Инспекция турындагы, шулай ук экспертлар, эксперт оешмалары турындагы мәгълүматларны җиткерергә тиешләр.

Башкару вакыты: тикшерүне үткәрүгә өч эш көненнән дә соңармыйча.

Эшнең нәтиҗәсе: юлланган тикшерүне үткәрү турындагы әмернамә.

5.4.4. Дәүләт төзелешен күзәтү урынга чыгып тикшерү формасында башкарыла.

Тикшерү тикшерүне үткәрү әмернамәсендә күрсәтелгән вазыйфа зат яисә вазыйфаи затлар тарафыннан гына тормышка ашырыла.

5.4.5. Объектка чыгар алдыннан тикшерүне үткәрүче вазыйфаи зат эшнең материаллары, шулай ук объектның проект документлары белән танышырга тиеш.

Тикшерүне үткәргәндә вазыйфаи зат түбәндәге эшләрне башкара:

а) хезмәт таныклыкларын күрсәтә һәм мәҗбүри тәртиптә җитәкчене яисә юридик затның башка вәкаләтле затын, шәхси эшмәкәрне, аның вәкаләтле затын тикшерүне үткәрү турындагы әмернамә һәм тикшерүне үткәрүче вазыйфаи затларның вәкаләтләре, шулай ук тикшерүнең максатлары, бурычлары, нигезләре, контроль буенча чараларның төрләре һәм күләмнәре, тикшерүгә җәлеп ителүче

экспертлар, эксперт оешмалары вәкилләренең составы, аны үткәрүнең вакытлары һәм шартлары белән таныштыра;

б) төзүче, техник заказчы, төзүне башкаручы зат тарафыннан тикшерүне үткәрү өчен күрсәтелгән эшләрнең башкарылышына (аерым эшләрне, төзелеш конструкцияләрен, инженер-техник тәэмин ителеш челтәрләре өлешләрен дә кертеп), һәм шулай ук төзелеш материалларын (эшләнмәләрен) кулланып эшләүгә бәйле документларны карый;

в) башкарылган эшләрне (аерым эшләрне, төзелеш конструкцияләрен, инженер-техник тәэмин ителеш челтәрләре өлешләрен дә кертеп) һәм кулланылган төзелеш материалларын (эшләнмәләрен) (алга таба – башкарылган эшләрне) визуаль күзәтеп чыга;

г) башкарылган эшләргә үткәрелгән тикшерүләрнең нәтиҗәләрен рәсмиләштерә;

д) РФ КоАП 9.4, 9.5, 9.5.1, 9.16 ст. 3 өл., 14.44, 19.4 ст. 1 өл., 19.4.1, 19.5 ст. 6 өл., 19.6, 19.7 статьяларында алар өчен җаваплылык каралган мәҗбүри таләпләрне бозуларны ачыклаган очракларда, Россия Федерациясенең административ хокук бозулар турындагы законнарында каралган тәртиптә, административ хокук бозуларга юл куйган затларны административ җаваплылыкка тартуга юнәлдерелгән эшләрне башкара.

Әлеге пунктның “б”, “в” пункт өлешләрендә каралган эшләрнең эзлеклелеге вазыйфаи затлар тарафыннан мөстәкыйль билгеләнә.

5.4.6. Тикшерүләрне үткәргәндә вазыйфа затлар тарафыннан түбәндәгеләр тикшерелә:

- үзен-үзе көйләүче оешмаларның эшләрне башкаруга рөхсәт итә торган таныклыгы булуы;

- башкарма документларның, шул исәптән аларны контрольдә тоту башка эшләрне башкарганнан соң, шулай ук сүтмичә яисә төзелеш конструкцияләрен һәм инженер-техник тәэмин ителеш челтәрләре өлешләренә зарар китермичә мөмкин булмаган, иминлеккә йогынты ясаучы эшләрне, конструкцияләрне, инженер-техник тәэмин ителеш челтәрләре өлешләрен карау актларының булуы һәм дөрес алып барылышы;

- башкарылучы эшләрнең, кулланылучы конструкцияләрнең, эшләнмәләрнең һәм җитештерелүче җайланманың проект карарларына, техник регламентларның, төзелеш нормаларының һәм кагыйдәләренең, техник шартларның һәм башка норматив документларның таләпләренә җавап бирүе;

- төзелештә кулланылучы конструкцияләрнең, эшләнмәләрнең һәм материалларның (техник паспортларның, сертификатларның, лаборатор эшләрнең нәтиҗәләрен һ.б.) сыйфатын раслаучы документларның булуын;

- башкарылучы төзелеш-монтаж эшләренең һәм кулланылучы конструкцияләрнең, эшләнмәләрнең, материалларның һәм җайланмаларның сыйфат мәсьәләләренә, аерым эшләрне, биналарның, корылмаларның һәм тулаем объектларның конструктив элементларын кабул иткәндә ачыкланган җитешсезлекләрне һәм эшләнеп бетмәгәннәрне вакытында хәл итүне тәэмин итүгә кагылышлы Инспекция боерыкларының, автор күзәтчелеге күрсәтмәләренең һәм кисәтүләренең үтәлешен;

- мондый бозуларны бетерү турындагы актлар төзелгәнчегә хәтле эшләрне дәвам иттерүгә керешүгә булган тыюның үтәлешен.

5.4.7. Башкарылган эшләргә һәм кулланылучы төзелеш материалларына тикшеренүләр, лаборатор һәм башка сынаулар үткәрү кирәк булган очракларда, Инспекция тарафыннан контроль буенча тиешле чаралар үткәрелә (билгеләнә), ә экспертларны яисә эксперт оешмаларын җәлеп итеп экспертизалар үткәрү кирәк булган очракта, Инспекция тарафыннан законнарда каралган тәртиптә тиешле белгечләр җәлеп ителә.

Экспертизаларны, тикшеренүләрне, лаборатор һәм/яки башка сынауларны үткәрүгә булган таләпләр Россия Федерациясе законнары нигезендә билгеләнә.

5.4.8. Төзелеш объектларында башкарылган эшләргә һәм кулланылучы төзелеш материалларына (эшләнмәләренә) тикшеренүләр, лаборатор һәм/яки башка сынаулар үткәрү белән бәйле тикшерүләрне тәэмин итү максатларында территориаль органнар, Тикшерүләрне үткәрү программасы кысаларында, шулай ук гамәлдәге тәртипләр белән рәсмиләштерелгән хәбәрнамәләр, мөрәҗәгатьләр һәм башка сораулар нигезендә, объективлыкны, дөреслекне тәэмин итү һәм контроль буенча чаралар барышында ачыкланган мәгълүматларның кабул ителгән проект карарларына туры килүен, һәм шулай ук аларның техник регламентларның һәм башка норматив-хокукый актларның таләпләренә ярашуын ачыклау өчен Экспертизаларны, тикшеренүләрне һәм сынауларны үткәрүне күзәтү буенча территориаль органны җәлеп итә.

5.4.9. Күзәтү объектында уртак тикшерүләрне тормышка ашыруга махсус бүлекчәне җәлеп итүне инициацияләү өчен объектта күзәтүне тормышка ашыруга җаваплы булган вазыйфаи зат үз территориаль органы җитәкчесе исеменә рәсми язу юллый, анда Экспертизаларны, тикшеренүләрне һәм сынауларны үткәрүне күзәтү буенча территориаль органны җәлеп итүнең инициациясе өчен нигез, аларны үткәрүнең вакытларын һәм объектның адресын, һәм шулай ук, кирәк булганда, мөмкин булган җитешсезлекләр һәм бозуларның характеры нигезендә, башка сыйфатламалырн күрсәтеп, инструменталь контроль үткәрүнең кирәкле төрләре күрсәтелә.

5.4.10. Алынган рәсми язу нигезендә территориаль орган җитәкчесе, территориаль органнарның Экспертизаларны, тикшеренүләрне һәм сынауларны үткәрүне күзәтү буенча территориаль орган белән үзара бәйләнешенең регламентында каралган тәртиптә, Экспертизаларны, тикшеренүләрне һәм сынауларны үткәрүне күзәтү буенча территориаль органны контроль тикшерүләрне үткәрүгә җәлеп итә.

5.4.11. Регламентның 2.4.1.2. пунктында күрсәтелгән нигез буенча урынга чыгып тикшерү Инспекция тарафыннан кичектергесез рәвештә, прокуратура органына хәбәр итеп, егерме дүрт сәгать эчендә 294-ФЗ номерлы Федераль законның 10 нчы статьясындагы 12 нче өлешендә билгеләнгән тәртиптә, түбәндәге документларны: юридик затны, шәхси эшмәкәрне планнан тыш урынга чыгып тикшерү үткәрүнең дәүләт күзәтчелеге органының прокуратура органы белән килештерелгәнлеге турындагы гаризаны (14 нче номерлы Кушымта); Инспекция башлыгының, башлык урынбасарының, Инспекция территориаль органы җитәкчесенең планнан тыш урынга чыгып тикшерү үткәрү турындагы әмернамәсенең күчермәсен; планнан тыш тикшерүне үткәрүгә нигез булган мәгълүматларны үз эченә алган документларны юллау аша тормышка ашырылырга мөмкин.

5.4.12. Җитәкче, башка вазыйфаи зат яисә юридик затның вәкаләтле заты, шәхси эшмәкәр, аның вәкаләтле заты соравы буенча Инспекциянең вазыйфаи

затлары тикшерелергә тиешле затларны әлеге Регламент белән таныштырырга тиеш.

5.4.5.-5.4.12 пунктларында каралган процедураларны үтәү вакыты егерме эш көненнән дә артык түгел.

Эшнең нәтиҗәсе: юридик затка, шәхси эшмәкәргә, физик затка карата үткәрелгән тикшерү.

5.4.13. Тикшерү нәтиҗәләре буенча Инспекциянең тикшерүне үткәрүче вазыйфаи затлары тарафыннан билгеләнгән формада ике нөсхәдә акт төзелә. (15 нче номерлы Кушымта – физик затлар өчен; 15 А номерлы Кушымта – юридик затлар һәм шәхси эшмәкәрләр өчен).

Тикшерү актына продукциянең үрнәкләрен алу турындагы беркетмәләр, үткәрелгән тикшеренүләрнең, сынауларның һәм экспертизаларның беркетмәләре һәм бәяләмәләре, мәҗбүри таләпләрне бозу өчен җаваплылык йөкләнгән юридик зат эшчеләренең, шәхси эшмәкәр эшчеләренең аңлатмалары, ачыкланган бозуларны бетерү турындагы күрсәтмәләр һәм тикшерү нәтиҗәләре белән бәйле башка документлар һәм аларның күчермәләре беркетелә.

Тикшерү акты ул тәмамланганнан соң турыдан-туры ике нөсхәдә рәсмиләштерелә, аларның берсе кушымталарның күчермәләре белән җитәкчегә, башка вазыйфаи затка яисә юридик затның вәкаләтле затына, шәхси эшмәкәргә, аның вәкаләтле затына тикшерү акты белән танышу яисә танышудан баш тартуы турындагы имзасы нигезендә бирелә.

Җитәкче, башка вазыйфаи зат яисә юридик затның вәкаләтле заты, шәхси эшмәкәр, аның вәкаләтле заты булмаган очракта, һәм шулай ук тикшерелүче зат тикшерү акты белән танышу яисә танышырга теләмәве турында язу бирүдән баш тарткан очракта, акт почта аша заказлы хат итеп тапшырылуы турындагы белдермәнамәсе белән берлектә җибәрелә, анысы объект буенча эштә саклanучы тикшерү акты нөсхәсенә теркәп куела.

Әгәр дә тикшерү актын төзү өчен үткәрелгән тикшеренүләр, сынаулар, экспертизалар нәтиҗәләре буенча бәяләмәләр алу кирәк булса, тикшерү акты контроль буенча чаралар үткәрелеп беткәннән соң төзелә, һәм җитәкчегә, башка вәкаләтле затка яисә юридик затның вәкаләтле затына, шәхси эшмәкәргә, аның вәкаләтле затына кулга алуы турындагы язу нигезендә тапшырыла яисә почта аша заказлы хат итеп кулга алу турындагы белдермәнамәсе белән юллана, анысы объект буенча эштә саклanучы тикшерү акты нөсхәсенә теркәп куела.

Әгәр дә планнан тыш урынга чыгып тикшерүне үткәрү өчен аны үткәрүне прокуратура органы белән килештерү таләп ителсә, тикшерү актының күчермәсе тикшерү актын төзү көненнән алып биш эш көне эчендә тикшерүне үткәрүне килештерү турындагы карарны кабул итүче прокуратура органына җибәрелә.

Башкару вакыты: Тикшерү акты ул тәмамланганнан соң турыдан-туры төзелә һәм тапшырыла, ә үткәрелгән тикшеренүләр, сынаулар, экспертизалар нәтиҗәләре буенча бәяләмә алу кирәк булганда, тикшерү акты контроль буенча чаралар үткәрелеп беткәннән соң өч эш көненнән артмаган вакыт эчендә төзелә һәм тапшырыла.

Эшнең нәтиҗәсе: тапшырылган (җибәрелгән) тикшерү акты.

5.4.14. Тикшерүнең нәтиҗәләре дәүләт төзелешен күзәтү органындагы вазыйфаи зат тарафыннан гомуми һәм/яки махсус журналларга теркәлә.

Тикшерүләрнең исәп журналында Инспекциянең вазыйфаи затлары тарафыннан үткәрелгән тикшерү турында, Инспекция турындагы

мәгълүматларны, тикшерүне үткәрүнең башланган һәм беткән көннәрен, аны үткәрү вакытын, тикшерүнең хокукый нигезләрен, максатларын, бурычларын һәм предметын, ачыкланган бозуларны һәм бирелгән күрсәтмәләрне үз эченә алган язу теркәлә, һәм шулай ук тикшерүне үткәрүче вазыйфа затның яисә вазыйфаи затларның фамилиясе, исеме, атасының исеме һәм вазыйфасы, аның яисә аларның имзалары да күрсәтелә.

Тикшерүләрнең исәп журналы тегелгән, номерланган һәм юридик затның, шәхси эшмәкәрнең мөһере белән таныкланган булырга тиеш.

Тикшерүләрнең исәп журналы булмаганда тикшерү актында тиешле язу теркәлә.

Башкару вакыты: турыдан-туры тикшерү беткәннән соң.

Эшнең нәтиҗәсе: тикшерүләр журналындагы язу.

5.4.15. Тикшерүне үткәргәндә бозулар ачыкланганда, тикшерүне үткәрүче вазыйфаи затлар Россия Федерациясе законнарында каралган вәкаләтләре кысаларында түбәндәгеләрне башкара:

1) юридик затка, шәхси эшмәкәргә ачыкланган бозуларны бетерү буенча, аларны бетерү вакытларын күрсәтеп, һәм (яки) кешеләрнең гомеренә, сәламәтлегенә булган зарарны, хайваннарга, үсемлекләргә, әйләнә-тирә мохиткә, Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларына (тарих һәм мәдәният һәйкәлләренә), дәүләт иминлегенә, физик һәм юридик затларның мөлкәтенә, дәүләти һәм муниципаль мөлкәткә, табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрне кисәтүгә, һәм шулай ук федераль законнарда каралган башка чараларга карата булган зыянны кисәтү буенча чаралар үткәреләчәге турында күрсәтмә бирүне (16 нчы номерлы Кушымта);

2) ачыкланган бозуларны бетерүне, аларны кисәтүне, гражданнарның гомеренә, сәламәтлегенә салынырга мөмкин булган зыянны, хайваннарга, үсемлекләргә, әйләнә-тирә мохиткә, Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларына (тарихи һәм мәдәни һәйкәлләргә), дәүләт иминлеген тәэмин итүгә, табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрне кисәтүгә карата зыянны булдырмый калуны контрольдә тоту буенча чаралар, һәм шулай ук Регламентның 5.4.5 пунктының “д” пункт өлешендә күрсәтелүче ачыкланган бозуларга юл куйган затларны җаваплылыкка тарту буенча чаралар күрүне (17 нче номерлы кушымта – административ хокук бозу турындагы беркетмә).

Тикшерүне үткәрү барышында юридик затның, аның филиалының, вәкиллегенең, структур бүлекчәсенең, шәхси эшмәкәрнең эшчәнлеге, алар тарафыннан биналарның, каралтыларның, корылмаларның, бүлмәләрнең, җайланмаларның, охшаш объектларның, транспорт чараларының эксплуатацияләнүе, алар тарафыннан җитештерелүче һәм урнаштырылучы товарлар (башкарылучы эшләр, күрсәтелүче хезмәтләр) турыдан-туры гражданнарның гомеренә, сәламәтлегенә зыян салу, хайваннарга, үсемлекләргә, әйләнә-тирә мохиткә, Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларына (тарихи һәм мәдәни һәйкәлләргә), дәүләт иминлегенә карата, табигый яисә техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр килеп чыгу белән янаганлыгы ачыкланса яисә мондый зыян салынса, Инспекциянең вазыйфаи затлары кичекмәстән зыян салынуга юл куймау буенча яисә аның салынуын туктату, әйләнештән гражданнарның гомеренә, сәламәтлегенә һәм әйләнә-тирә мохиткә куркыныч янаучы продукциянең бәяләмәләрен булдырмау буенча, РФ КоАП билгеләнгән тәртиптә, юридик затның, аның филиалының, вәкиллегенең,

структур бүлекчәсенең, шәхси эшмәкәрнең эшчәнлеген вакытлыча тыюга кадәр чаралар күрә, һәм шулай ук төрле үтемле ысул белән гражданнарга, башка юридик затларга, шәхси эшмәкәрләргә зыян салыну куркынычы барлыгы һәм аны бетерү юллары турындагы мәгълүматны җиткерә.

Башкару вакыты: хокук бозу ачыклангannан соң турыдан-туры.

Эшнең нәтиҗәсе: төзелгән тикшерү акты, бозулар ачыкланганда: административ хокук бозу турында беркетмә, ачыкланган бозуларны бетерү турында күрсәтмә.

5.4.16. Ачыкланган бозуларны бетергәннән соң төзүче, техник заказчы, төзүне башкаручы зат Инспекциягә ачыкланган бозуларны бетерү турындагы хәбәрнамәне җибәрә (18 нче номерлы Кушымта).

Әлеге хәбәрнамә вазыйфаи затлар тарафыннан бозуларны бетерү буенча бирелгән күрсәтмәләрнең үтәлешен тикшерүгә нигез булып тора.

5.5. “Соңгы тикшерү” административ процедурасы.

5.5.1. Объектны төзү, объект төзелеше барышында төзелеш материаллары (эшләнмәләре) кулланылышында җибәрелгән барлык бозуларны бетерү фактта тәмамланганнан соң, һәм шулай ук объектның төзелеше буенча барлык эшләрне башкару белән бәйле булган башкарма документларны рәсмиләштергәннән соң, төзүче (техник заказчы) Инспекциягә капиталь төзелеш объектының төзелеше, үзгәртеп корылышы тәмамлану турында хәбәрнамә – алга таба – хәбәрнамә юллый (19 нчы номерлы Кушымта).

5.5.2. Документ әйләнешен теркәү һәм алып баруга җаваплы булган вазыйфаи зат Инспекциягә (территориаль органга) кергән хәбәрнамәне “Электрон Хөкүмәт” системасында һәм “ТР Төзелеш күзәтчелеге” ЭИСында терки һәм аны тиешле территориаль органга тапшыра.

Башкару вакыты: алган көннән башлап бер эш көне дәвамында.

Эшнең нәтиҗәсе: “Электрон Хөкүмәт” системасында һәм “ТР Төзелеш күзәтчелеге” ЭИСында теркәлгән хәбәрнамә.

5.5.3 Территориаль орган җитәкчесе (җитәкчесенең урынбасары) хәбәрнамәне объектта күзәтүне башкаруга җаваплы булган вазыйфаи затка тапшыра.

Башкару вакыты: хәбәрнамәне алган көннән алып бер эш көненнән дә соңга калмыйча.

Эшнең нәтиҗәсе: объектта күзәтүне башкаруга җаваплы булган вазыйфаи затка җибәрелгән хәбәрнамә.

5.5.5. Объектта күзәтүне тормышка ашыруга җаваплы булган вазыйфаи зат төзелгән, үзгәртеп корылган капиталь төзелеш объектының техник регламентларның (нормаларның һәм кагыйдәләрнең), башка норматив-хокукый актларның һәм проект документларының таләпләренә ярашуын соңгы тикшерүне (алга таба – соңгы тикшерү) оештыра (билгели) һәм Регламентның 5.4.1-5.4.3 пунктларында каралган эшләрне башкара.

Башкару вакыты: алдагы процедура тәмамланган көннән башлап 7 көн эчендә.

Эшнең нәтиҗәсе: соңгы тикшерүнең билгеләнүе.

5.5.6. Вазыйфаи затлар соңгы тикшерүне Регламентның 5.4.5-5.4.15 пунктлары нигезендә үткәрә, техник регламентларның (нормаларның һәм кагыйдәләрнең), башка норматив-хокукый актларның, проект документларының

ачыкланган бозулары буенча аларны соңгы тикшерү актына үз имзалары белән кертү юлы белән үзләренең кисәтүләрен җиткерә.

Соңгы тикшерүнең акты соңгы тикшерүне үткәрүче вазыйфаи затлар тарафыннан ике нөсхәдә (бер нөсхәсе төзүчегә (техник заказчыга) бирелә, икенчесе дәүләт төзелешен күзәтү органы эшендә кала) әзерләнә һәм имзалана.

5.5.7. Кисәтүләре булган (булган очракта) соңгы тикшерү акты һәм бозуларны бетерү буенча күрсәтмә объектта күзәтүне тормышка ашыруга җаваплы булган вазыйфаи зат тарафыннан Регламентның 5.4.13 пунктында каралган тәртиптә төзүчегә (техник заказчыга) юллана.

Соңгы тикшерү акты алынганнан соң һәм кисәтүләр бетерелгәннән соң төзүче (техник заказчы) Регламентның 5.4.16, 5.5.1 пунктларында күрсәтелгән эшләрне башкара.

5.5.8. Соңгы тикшерү акты (кисәтүләре булмаган) төзүче яисә техник заказчы тарафыннан төзелгән, үзгәртеп корылган капиталь төзелеш объектының техник регламентларның (нормаларның һәм кагыйдәләрнең), башка норматив-хокукый актларның һәм проект документларының таләпләренә, шул исәптән энергия нәтиҗәлелеге таләпләренә һәм капиталь төзелеш объектының энергия ресурсларын исәпләү буенча кулланылучы исәп җайланмалары белән тәэмин ителешенә кагылышлы таләпләргә ярашуы турындагы бәяләмәне (алга таба - ЯТБ) сорау буенча мөрәҗәгать итүгә нигез булып тора.

Төзүче яисә техник заказчы ЯТБ сорап мөрәҗәгать иткәндә, кисәтүләре булган соңгы тикшерү акты ЯТБ бирүдән баш тарту карарын кабул итүгә нигез булып тора.

5.5.9. ЯТБ бирү яисә ЯТБ бирүдән баш тарту турындагы карар Татарстан Республикасы Дәүләт төзелешен күзәтү инспекциясенең 23.01.2012ел, 3 нче номерлы боергы (ТР Юстиция министрлыгында 05.04.2012 ел, 1466 номеры белән теркәлгән) белән расланган капиталь төзелеш объектының техник регламентларның (нормаларның һәм кагыйдәләрнең), башка норматив-хокукый актларның һәм проект документларының таләпләренә, шул исәптән энергия нәтиҗәлелеге таләпләренә һәм капиталь төзелеш объектының энергия ресурсларын исәпләү буенча кулланылучы исәп җайланмалары белән тәэмин ителешенә кагылышлы таләпләргә ярашуы турындагы бәяләмәне бирү буенча дәүләт хезмәтен күрсәтүнең Административ регламенты белән көйләнә.

## 6. Дәүләт төзелешен күзәтүне тормышка ашыруның тәртибе һәм формалары

6.1. Әлеге регламент кагыйдәләре үтәлешенең агымдагы контроле, дәүләт төзелешен күзәтүне тормышка ашыруның тулылыгы һәм сыйфаты белән, Инспекция һәм аның территориаль органнарындагы вазыйфаи затларның карарлар кабул итүе белән, башлык, аның урынбасарлары, территориль органнарындагы җитәкчеләре һәм аларның урынбасалары тарафыннан тормышка ашырыла.

6.2. Агымдагы контроль Инспекция һәм аның территориаль органнарындагы вазыйфаи затлары тарафыннан ай саен тапшырылучы хисаплылыкны анализлау юлы, шулай ук Инспекция һәм аның территориаль органнарындагы вазыйфаи затларның бурычларын башкаруына даими тикшерүләр үткәрү юлы белән тормышка ашырыла.

6.3. Дәүләт төзелешен күзәтүне тормышка ашыруның тулылыгын һәм сыйфатлылыгын контрольдә тоту дәүләт төзелешен күзәтүне тормышка ашырган вакытта вазыйфаи затның эшенә (гамьсезлегенә) карата шикаятьләр килгәндә хезмәт тикшерүләрен үткәрүне үз эченә ала.

6.4. Хезмәт тикшерүләре Россия Федерациясенең гамәлдәге законнарындагы таләпләр нигезендә тормышка ашырыла.

6.5. Дәүләт төзелешен күзәтүне тормышка ашырганда башкарган эшләре (гамьсезлеге), кабул иткән карарлары өчен Инспекциянең һәм аның территориаль органнарының вазыфаи затлары Россия Федерациясенең гамәлдәге законнарында билгеләнгән тәртиптә җаваплылыкка тартыла.

6.6. Гражданнар, аларның берләшмәләре һәм оешмалары тарафыннан иҗтимагый контроль булдыруны тәэмин итү максатларында, хезмәт тикшерүе конкрет мөрәҗәгать буенча үткәрелгән очракта, үткәрелгән хезмәт тикшерүе нәтиҗәләре буенча кабул ителгән карарлар турында гариза бирүчегә хәбәр ителә.

6.7. Россия Федерациясе законнарын бозуда гаепләнүче вазыйфаи затларга карата кабул ителгән чаралар турында Инспекция яисә аның территориаль органнары, мондый чараларны кабул иткән көннән башлап ун көн эчендә, хокуклары һәм (яки) законлы ихтыяҗлары бозылучы юридик затка, шәхси эшмәкәргә язмача формада хәбәр итәләр.

## 7. Дәүләт функциясен башкаручы органның, шулай ук аның вазыйфаи затларының карарларына һәм эшләренә (гамьсезлекләренә) судка кадәр (судтан гайре) шикаять бирү тәртибе

7.1. Юридик затлар, шәхси эшмәкәрләр, физик затлар (алга таба – гариза бирүчеләр) дәүләт төзелешен күзәтүне тормышка ашыру барышында кабул ителгән һәм башкарылган Инспекция һәм аның территориаль органнары, аларның вазыйфаи затлары карарларына һәм эшләренә (гамьсезлекләренә) карата, югарыда торучы вазыйфаи затка буйсынучанлык хәлендәге тәртиптә, судка кадәр (судтан гайре) шикаять бирү хокукына ия.

7.2. Гариза бирүче кәгазьдә язмача формада яисә электрон төстә шикаять белән мөрәҗәгать итәргә, почта аша тиешенчә яисә Инспекциянең сайты (htpp://gsn.tatarstan.ru) аша Интернетның мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән файдаланып шикаять җибәрергә, шулай ук Инспекциягә һәм аның территориаль органнарына шәхси мөрәҗәгать иткәндә шикаять бирергә хокуклы.

7.3. Инспекциянең һәм аның территориаль органнарының, аларның вазыйфаи затларының эшләре (гамьсезлеге) һәм алар тарафыннан дәүләт функциясен үтәгәндә кабул ителгән (кабул ителүче) карарлар судка кадәр (судтан гайре) шикаять бирүнең предметы булып тора.

7.4. Инспекциягә (территориаль органнарына) яисә вазыйфаи затка аларның җаваплылыгына ярашлы килгән шикаять һичшиксез каралырга тиешле. Судка кадәр (судтан гайре) шикаятьне караудан баш тарту яисә туктату өчен нигезләр каралмаган.

7.5. Шикаять түбәндәгеләрне үз эченә алырга тиеш:

1) дәүләт төзелешен күзәтүне башкаручы территориаль органның исеме һәм (яисә) карарлары, эше (гамьсезлеге) шикаять ителүче вазыйфаи затның вазыйфасы, фамилиясе, исеме, атасының исеме;

2) юридик затның исеме; шәхси эшмәкәрнең, физик затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта); урнашкан урыны; әгәр җавап электрон документ формасында җибәрелергә тиеш булса электрон почта адресы, һәм, әгәр җавап язмача формада җибәрелергә тиеш булса - почта адресы.

3) Инспекциянең (территориаль органнарының), аның вазыйфаи затларының шикаять ителүче карарлары һәм эшләре (гамьсезлекләре) турындагы белешмәләр;

4) аның нигезендә Инспекциянең, аның вазыйфаи затларының карарлары һәм эшләре (гамьсезлекләре) белән юридик зат риза булмаган дәлилләр;

5) имза һәм дата.

Шикаятькә шикаятьтә бәян ителгән хәлләрне раслаучы документларның күчермәләре дә беркетелергә мөмкин. Ул очракта шикаятьтә аңа беркетелүче документларның исемлеге күрсәтелә.

7.6. Шикаятькә түбәндәге очракларда җавап бирелми:

язмача шикаятьтә җавап җибәрелергә тиешле почта адресы (электрон адрес) күрсәтелмәгән булса;

язмача шикаять текстын укып булмаса, аңа җавап бирелми һәм ул аныңөчен җаваплы булган вазыйфаи затка карау өчен юлланылмый, бу хакта шикаятьне теркәгән көннән алып җиде көн эчендә шикаятьне юллаган гариза бирүчегә хәбәр ителә, әгәр дә аның исеме, фамилиясе һәм почта адресы укылышлы булса;

гариза бирүченең шикаятендә аның тарафыннан моңарчы җибәрелгән шикаятьләргә берничә тапкыр җавап бирелгән сорау каралып, ул сорауның мәгънәсенә карата күп тапкыр язмача җаваплар бирелгән булса, һәм шул ук вакытта шикаятьтә яңа дәлилләр яки шартлар китерелмәсә, башлык (башлык урынбасарлары), вазыйфаи зат чираттагы шикаятьнең нигезсез булуы турында карар кабул итәргә һәм, әлеге шикаятьнең Инспекциягә юлланган булуы очрагында, гариза бирүче белән әлеге мәсьәлә буенча язышуларны туктатырга хокуклы. Әлеге карар турында шикаятьне юллаган гариза бирүчегә хәбәр ителә;

эчтәлегендә әдәпсез яисә кимсетүче тәгъбирләр, вазыйфаи затның гомеренә, сәламәтлегенә һәм мөлкәтенә, шулай ук аның гаилә әгъзаларына янаулар булган шикаятьне алганда Инспекциянең (территориаль органның) вазыйфаи заты шикаятьне анда каралган мәсьәләрнең асылы буенча җавап бирмичә калдырырга һәм гариза бирүчегә хокуклар белән килешмәвенең тиешле булмавы хакында хәбәр итәргә хокуклы.

Әгәр дә шикаятьтә әзерләнүче, башкарылучы яисә башкарылган хокукка каршы эшләр турында, шулай ук аны әзерләүче, башкаручы яки башкарган зат турында белешмәләр булса, әлеге шикаять моның өчен җаваплы булган дәүләт органына юлланырга тиеш.

Суд карарына карата шикаять теркәлгән көннән алып җиде көн эчендә, әлеге суд карарын шикаять кылу тәртибе аңлатылып, гариза бирүчегә кире җибәрелә.

Әгәр дә шикаятьтә куелган сорауның асылына карата дәүләт яисә федераль закон белән саклана торган башка сер турындагы белешмәләрне таратмыйча җайвап биреп булмаса, шикаятьне юллаган гариза бирүчегә әлеге белешмәләрне

тарату мөмкин булмавы сәбәпле куелган сорауның асылына карата җавап биреп булмаганлыгы турында хәбәр ителә.

Әгәр дә шикаятьтә каралган сорауларның асылына карата җавап бирү мөмкинлеге булмаган сәбәпләр киләчәктә бетерелсә, гариза бирүче шикаятьне Инспекциягә яисә аның вазыйфаи затына кире юлларга хокуклы.

7.7. Инспекциянең, аның вазыйфаи затының эшенә (гамьсезлегенә), һәм дәүләт төзелешен күзәтүне башкарганда алар тарафыннан кабул ителгән (кабул ителүче) карарларга карата шикаятьнең Инспекциягә керүе шикаятьне судка кадәр (судтан гайре) карау процедурасын башлау өчен нигез булып тора.

7.8. Юридик затлар, шәхси эшмәкәрләр, физик затлар шикаятьне карау өчен һәм нигезләү өчен кирәкле мәгълүматларны һәм документларны алуга хокуклы. Мондый төрдәге мәгълүматны һәм документларны алу өчен юридик затлар, шәхси эшмәкәрләр, физик затлар Инспекция адресына язмача яисә электрон формада тиешле сорауны юлларга тиеш. Инспекциянең вазыйфаи затлары юридик затка, шәхси эшмәкәргә, физик затка турыдан-туры аның хокукларына һәм ирегенә кагылышлы документлар һәм материаллар белән танышу мөмкинлеген бирергә тиеш, әгәр дә мәгълүматка карата Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән чикләүләр каралмаган булса.

7.9. Инспекциядә вазыйфаи затларның эшенә (гамьсезлегенә) карата шикаять Инспекция башлыгына юлланырга мөмкин. Инспекциянең һәм аның башлыгының эшенә (гамьсезлегенә), карарларына карата шикаять Татарстан Республикасының Министрлар Кабинетына юлланырга мөмкин.

7.10. Шикаять Инспекция тарафыннан аның теркәлү көненнән алып утыз көн эчендә карала.

7.11. Шикаятьне судка кадәр (судтан гайре) карауның нәтиҗәләре булып түбәндәгеләр тора:

1) дәүләт төзелешен күзәтүне башкарганда кабул ителгән (кабул ителүче) карарларга һәм эшләргә карата шикаятьне судка кадәр (судтан гайре) карауны канәгатьләндерү, ә атап әйткәндә:

а) хезмәт тикшерүе барышында хезмәт вазыйфаларын җиренә җиткереп башкармау фактлары ачыкланган очракта вазыйфаи затка (вазыйфаи затларга) карата Россия Федерациясе законнары нигезендә чаралар күрү;

б) Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының законнарын бозуда гаепләнүче вазыйфаи затларга карата чаралар кабул ителү турында, мондый чараларны кабул итү көненнән башлап ун көн эчендә хокуклары һәм (яки) законлы ихтыяҗлары бозылган гаиза бирүчегә язмача формада хәбәрнамә җибәрү;

2) гариза бирүчегә мондый карарның дәлилләнгән нигезләре белән язмача формада хәбәр итеп, дәүләт төзелешен күзәтү барышындагы эшләргә (гамьсезлеккә) һәм кабул ителгән карарларга карата судка кадәр (судтан гайре) бирелгән шикаятьне канәгатьләндермәү.

**1 нче номерлы Кушымта**

*(Экологик, технологик һәм атом күзәтчелеге буенча федераль хезмәтнең 2006 елның 26 декабреннән “Капиталь төзелеш объектларының төзелеше, үзгәртеп корылышы, капиталь төзекләндерелешендәге башкарма документларны алып баруның составына һәм тәртибенә карата Таләпләрне һәм эшләрне, конструкцияләрне, инженер-техник тәэмин ителеш челтәрләре өлешләрен карап чыгу актларына карата таләпләрне раслау һәм кулланылышка кертү турында”гы 1128 номерлы боерыгы белән расл.).*

Капиталь төзелеш объекты ____________________________________________

____________________________________________________________________

____________________________________________________________________

____________________________________________________________________

*(капиталь төзелеш объектының исеме, почта яисә төзелеш адресы)*

Төзүче яисә заказчы__________________________________________________

____________________________________________________________________

*(юридик затлар өчен - дәүләт теркәве таныклыгының исеме,номеры һәм бирелү көне,*

____________________________________________________________________

____________________________________________________________________

*ОГРН, ИНН, почта реквизитлары, телефон/факс;*

____________________________________________________________________

____________________________________________________________________

*физик затлар өчен - фамилиясе, исеме,атасының исеме, паспорт күрсәткечләре,яшәгән урыны, телефон/факс)*

Төзүне башкаручы зат________________________________________________

*(юридик затлар өчен - дәүләт теркәве таныклыгының исеме, номеры һәм бирелү көне*

____________________________________________________________________

____________________________________________________________________

*ОГРН, ИНН, почта реквизитлары, телефон/факс;*

____________________________________________________________________

____________________________________________________________________

*физик затлар өчен - фамилиясе, исеме,атасының исеме, паспорт күрсәткечләре,яшәгән урыны, телефон/факс)*

Проект документларын әзерләүче зат ______________________________________

____________________________________________________________________

*(юридик затлар өчен - дәүләт теркәве таныклыгының исеме, номеры һәм бирелү көне*

____________________________________________________________________

____________________________________________________________________

*ОГРН, ИНН, почта реквизитлары, телефон/факс;*

____________________________________________________________________

____________________________________________________________________

*физик затлар өчен - фамилиясе, исеме,атасының исеме, паспорт күрсәткечләре,яшәгән урыны, телефон/факс)*

Геодезия нигезен коруны эшләгән төзүне башкаручы зат

____________________________________________________________________

____________________________________________________________________

*(юридик затлар өчен - дәүләт теркәве таныклыгының исеме, номеры һәм бирелү көне*

____________________________________________________________________

*ОГРН, ИНН, почта реквизитлары, телефон/факс;*

____________________________________________________________________

____________________________________________________________________

___________________________________________________________________________

___________________________________________________________________________

*физик затлар өчен - фамилиясе, исеме,атасының исеме, паспорт күрсәткечләре,яшәгән урыны, телефон/факс)*

**Капиталь төзелеш объектының геодезия нигезен коруны карау АКТы**

№_________________ «___»_______________20__ел.

Төзүче яисә заказчының вәкиле_____________________________________________

*(вазыйфасы, фамилиясе, инициаллары, вәкиллек итү турындагы документның реквизитлары)*

___________________________________________________________________________

___________________________________________________________________________

Төзүне башкаручы затның вәкиле____________________________________________
Төзүне башкаручының төзелеш контроле мәсьәләләре буенча вәкиле___________________________________________________________________

___________________________________________________________________________

___________________________________________________________________________

*(вазыйфасы, фамилиясе, инициаллары, вәкиллек итү турындагы документның реквизитлары)*

Проект документларын әзерләүче зат вәкиле _________________________________

___________________________________________________________________________

___________________________________________________________________________

*(вазыйфасы, фамилиясе, инициаллары, вәкиллек итү турындагы документның реквизитлары)*

Геодезия нигезен коруны эшләгән төзүне башкаручы затның вәкиле___________________________________________________________________

___________________________________________________________________________

___________________________________________________________________________

*(вазыйфасы, фамилиясе, инициаллары, вәкиллек итү турындагы документның реквизитлары)*

Төзелеш өчен геодезия нигезен коруга карата документларны карадылар

___________________________________________________________________________

___________________________________________________________________________

___________________________________________________________________________

___________________________________________________________________________

*(капиталь төзелеш объектының исеме)*

һәм җирлектә әлеге нигезнең беркетелгән билгеләрен тикшереп чыктылар.

Карау өчен тапшырылган төзелеш өчен геодезия нигезен коруның билгеләре, аларның координаталары, тамгалары, урнаштыру урыннары һәм беркетү ысуллары проект документларының, шулай ук техник регламентларның (нормаларның һәм кагыйдәләрнең), башка норматив-хокукый актларның таләпләренә җавап бирә

___________________________________________________________________________

___________________________________________________________________________

*(сызымның номеры, башка реквизитлары, проект документларының исеме,*

___________________________________________________________________________

___________________________________________________________________________

*проект документлары бүлеген башкаручы затлар турында мәгълүматлар,*

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________

*Техник регламент(нормалар һәм кагыйдәләр), башка норматив-хокукый актлардагы) статьяларының (пунктларның) исеме)*

һәм корылышларның һәм үлчәнешләрнең алдан билгеләнгән төгәллеген саклау белән башкарылган.

Өстәмә мәгълүматлар ______________________________________________

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________

Акт _______ нөсхәдә төзелде.

Кушымталар:___________________________________________________________

*(сызымнар, схемалар,исемлекләр һ.б.)*

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________

Төзүченең яки заказчының вәкиле_______________________________________

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________

*(вазыйфасы, фамилиясе, инициаллары, имзасы)*

Төзүне башкаручы затның вәкиле________________________________________

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________

*(вазыйфасы, фамилиясе, инициаллары, имзасы)*

Төзелешне башкаручы затның төзелеш контроле мәсьәләләре буенча вәкиле

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________

*(вазыйфасы, фамилиясе, инициаллары, имзасы)*

Проект документларын әзерләүче затның вәкиле ______________________________

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________

*(вазыйфасы, фамилиясе, инициаллары, имзасы)*

Геодезия нигезен коруны эшләгән төзүне башкаручы затның вәкиле_____________

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________

*(вазыйфасы, фамилиясе, инициаллары, имзасы)*

**2 нче номерлы Кушымта**

*(Экологик, технологик һәм атом күзәтчелеге буенча федераль хезмәтнең 2006 елның 26 декабреннән "Капиталь төзелеш объектларының төзелеше, үзгәртеп корылышы, капиталь төзекләндерелешендәге башкарма документларны алып баруның составына һәм тәртибенә карата Таләпләрне һәм эшләрне, конструкцияләрне, инженер-техник тәэмин ителеш челтәрләре өлешләрен карап чыгу актларына карата таләпләрне раслау һәм кулланылышка кертү турында"гы 1128 номерлы боерыгы белән расл.)*

Капиталь төзелеш объекты ____________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________

*(капиталь төзелеш объектының исеме, почта яисә төзелеш адресы)*

Төзүче яки заказчы___________________________________________________

*(юридик затлар өчен - дәүләт теркәве таныклыгының исеме, номеры һәм бирелү көне*
______________________________________________________________________

*ОГРН, ИНН, почта реквизитлары, телефон/факс;*
______________________________________________________________________

*физик затлар өчен - фамилиясе, исеме,атасының исеме, паспорт күрсәткечләре,яшәгән урыны, телефон/факс)*

Төзүне башкаручы зат_________________________________________________

*(юридик затлар өчен - дәүләт теркәве таныклыгының исеме, номеры һәм бирелү көне*
______________________________________________________________________

*ОГРН, ИНН, почта реквизитлары, телефон/факс;*
______________________________________________________________________

*физик затлар өчен - фамилиясе, исеме,атасының исеме, паспорт күрсәткечләре,яшәгән урыны, телефон/факс)*

Проект документларын әзерләүче зат ______________________________________

*(юридик затлар өчен - дәүләт теркәве таныклыгының исеме, номеры һәм бирелү көне*
______________________________________________________________________

*ОГРН, ИНН, почта реквизитлары, телефон/факс;*
______________________________________________________________________

*физик затлар өчен - фамилиясе, исеме,атасының исеме, паспорт күрсәткечләре,яшәгән урыны, телефон/факс)*

Җирлектә капиталь төзелеш объектының күчәрләрен кору эшләрен эшләгән, төзүне башкаручы зат _____________________________________________

*(юридик затлар өчен - дәүләт теркәве таныклыгының исеме, номеры һәм бирелү көне*
______________________________________________________________________

*ОГРН, ИНН, почта реквизитлары, телефон/факс;*
______________________________________________________________________

*физик затлар өчен - фамилиясе, исеме,атасының исеме, паспорт күрсәткечләре,яшәгән урыны, телефон/факс)*

**Җирлектә капиталь төзелеш объектының күчәрләрен кору**
**АКТы**

№_________________ «___»______________200__ел.

Төзүченең яки заказчының вәкиле________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
*(вазыйфасы, фамилиясе, инициаллары, вәкиллек итү турындагы документның реквизитлары)*

Төзүне башкаручы затның вәкиле__________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
*(вазыйфасы, фамилиясе, инициаллары, вәкиллек итү турындагы документның реквизитлары)*

Төзүне башкаручының төзелеш контроле мәсьәләләре буенча вәкиле__________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
*(вазыйфасы, фамилиясе, инициаллары, вәкиллек итү турындагы документның реквизитлары)*

Проект документларын әзерләүче затның вәкиле __________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
*(вазыйфасы, фамилиясе, инициаллары, вәкиллек итү турындагы документның реквизитлары)*

Җирлектә капиталь төзелеш объектының күчәрләрен кору эшләрен эшләгән, төзелешне башкаручы затның вәкиле______________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
*(вазыйфасы, фамилиясе, инициаллары, вәкиллек итү турындагы документның реквизитлары)*

Капиталь төзелешнең _______________________________________________
*(капиталь төзелеш объектының исеме)*

күчәрләре табигый үрнәктә корылганлыгы турында чын актны төзеделәр
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________

Шул ук вакытта шунысы билгеләнде:

1. Кору түбәндәге күрсәткечләр буенча башкарылган
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
*(сызымның номеры, башка реквизитлары, проект документларының исеме)*

2. Күчәрләрне беркетү
башкарылган____________________________________________________________

